КЫЙММӘТЛЕ БӘЙРӘМ

Балалар уены зурларның баш бәласенә әйләнмәсен өчен нишләргә?

> 16

«ВТ» УКУЧЫЛАРЫ:

«Бүләк өчен әле дә рәхмәт укыйбыз»

> 17

ОЛЕГ ФАЗЫЛҖАНОВ:

«Иң борчыганы – тәҗрибә куюлар артып китте. Үзгәртеп корулар тәңкәгә тия башлады»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 185 (29152) | Җомга | 15 декабрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

kremlin.ru

ДӨРЕС ЮЛ

ИЛБАШЫ ТАТАРСТАННЫ МАКТАДЫ ҺӘМ ХАЛЫККА РӘХМӘТ ӘЙТТЕ

Махсус хәрби операциядә катнашучыларга ярдәм җыйган халыкка – рәхмәт, Татарстанга – афәрин, М12 юлына – игътибар. Россия Президенты Владимир Путинның халык һәм журналистлар белән «туры элемтә»се узды. Дүрт сәгать тә дүрт минут дәвам иткән аралашу барышында Илбашы 67 сорауга җавап бирде. Чарада яңгыраган төп фикерләрне сезгә тәкъдим итәбез.

> 2

Ишетми калмагыз

Татарстанда дүртенче ай рәттән эшсезлек күрсәткече кими. Ноябрьдә бу сан, 0,2 процентка кимеп, 0,24% (октябрьдә – 0,26%) тәшкил иткән. Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәгълүматлары буенча, ноябрьдә республикада 4911 эшсез (шул ук вакытта буш вакансияләр саны – 54336) исәптә торган, октябрьдә исә 5286 кеше булган.
Эшсезлек дәрәҗәсе иң югары район-шәһәрләр өлеге үзгәрешсез калган: Югары Ослан, Түбән Кама районы һәм Казан. Ә менә Кайбыч, Тәтеш һәм Лаеш районнарында эш таба алмый йөрүчеләр кайдагыга караганда да азрак.

Декабрьдәге зыкы суыклар Татарстанның сәнәгать предприятиеләре эшенә, йортлардагы җылылыкка тискәре йогынты ясамаган. Табигый газ белән тәэмин итүдә өзеклекләр булмаган чөнки. Шул ук вакытта суык көннәрдә кулланучыларга җибәрелгән тәүлеклек газ күләме берничә тапкыр рекорд куйган. 11 декабрьдә иң зур күрсәткеч теркәлгән: бу көнне 83,3 куб метр күләмендә газ ягылган. Шуның 20,8 миллион кубыннан – халык һәм коммуналь-көнкүреш өлкәсе, 62,5 миллион кубыннан предприятиеләр файдаланган. Моңа кадәрге рекорд узган елның 11 гыйнварында куелган булган. Ул чагында 79,8 миллион куб метр күләмендә газ тотылган.

Россиядә финанс пирамидалары саны бер ел эчендә моңарчы күрелмәгән күрсәткечкә – 50 процентка арткан. Үзәк банкның «кара» исемлегендә 2 меңнән артыграк шундый проект исәпләнә.
Үзәк банк быел 9 ай эчендә узган елның шушы ук чорындагыга (1,4 мең ялган проект) караганда 47 процентка күбрәк пирамиданың эзенә төшкән.
Финанс пирамидаларының яртысыннан артыграгын законсыз эшләүче компанияләр һәм мошенниклыкка корылган проектлар алып тора. Шул ук вакытта 98 проценты интернет аша эш алып бара.
Белгечләр әйтүенчә, пирамидалар саны артуны халыкның өстәмә керемгә, акчаны бик отышлы урнаштыруга кызыгуы белән аңлатырга мөмкин.

Сындыра. Республикада бу атна ахыры – киләсе атна башында җылыта башлаячак. КФУ профессоры Юрий Переведенцев әйтүенчә, циклон (немец белгечләре аңа «Ваня» дигән исем биргән) һава температурасы артуга, явым-төшемгә китерәчәк.
Профессор сүзләренә караганда, киләсе дүшәмбе һәм сишәмбе – 18, 19 декабрьдә һава температурасы –2 градуска гына калачак. Кар-буран, көчле җил көтелә. Төнге сәгатьләрдә һава температурасы –12 градус чамасы тәшкил итәчәк.

kremlin.ru

ДӨРЕС ЮЛ

Татарстан турында

БРИКС саммитын үткәрү урыны итеп ни өчен нәкъ менә Казан сайланды?

– Татарстан яхшы үсеш алган. Ә аның башкаласы Казан – әлеге үсешнең яхшы үрнәкләренең берсе. Биредә моның өчен бөтен шартлар тудырылган. Элеккеге Президент та, хәзер җитәкчелек иткән Миңнехановы та әйбәт эшли. Хәтерлим, Минтимер Шәймиев белән бергә йортларда йөрдек. Бу 2000 нче еллар башы иде. Ул вакытта мине сөендергәне шул: әлеге торакларны йорт дип тә атарлык түгел, чыпчын «землянка»лар. Әмма эчтә – пөхтәлек. Миндә әле дә шундый шартларда тәртип саклый алган кешеләргә карата хөрмәт хисе яши. Аңлыйсызмы: бу – халыкның эчке культурасы дәрәҗәсе. Шаккатырмый, ә хөрмәт уята бу. Татарстанның уңышлы үсеше менә шунда чагыла да инде. Биредә барысы да яхшы хәлдә, инфраструктура үсеш алган. Казан халыкара дәрәҗәдәге спорт һәм сәяси чаралар үткәрде һәм аның тарту көченә әверелеп баруы табигый. Татарстан – күпмилләтле, күпдинле республика. Биредә төрле диннәр арасындагы мөнәсәбәтләр тиешле дәрәҗәдә корылган. Бу – бөтен ил өчен яхшы үрнәк. Казанны сайлавыбыз менә шуңа бәйле.

(«Татар-информ» хәбәрчесе биргән сорауга җавабы)

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Махсус хәрби операция турында

Аптырарлык түгел: Владимир Путинга килеп ирешкән сорауларның күпчелеге (шул исәптән сөйләшүнең күп вакыты да) махсус хәрби операциягә багышланган иде. Шунысы төгәл аңлашылды: махсус хәрби операциянең бурыч-максатлары үзгәрмәде. Тынычлыкны да әнә шул бурыч-максатлар үтәлгәч котәргә кирәк.

Ут йотып яшәгән халыкны да тынычландырды дәүләт җитәкчесе: мобилизациянең яңа дулкыны көтелми. Владимир Путин китергән саннарга күз салсаң, хәзерге вакытта 486 мең кеше үз теләге белән хәрби хезмәт үтү өчен контракт төзегән. Көн саен 1,5 мең ир-ат Россия Кораллы Көчләренә хезмәт итәргә дип килешү төзи, ди дәүләт башлыгы. «Кулларына корал тотып Ватанны сакларга теләүчеләр агымы туктамый», – диде Путин.

Ил башлыгы үз чыгышында тәүге тапкыр тагын бер санны яңгыратты. «Махсус хәрби операция зонасында 617 мең Россия хәрбие бар», – диде ул.

Владимир Путин хәрбиләргә дигән ярдәм чаралары, шул исәптән үз ихтыярлары белән хезмәткә алынучыларга да, бер үк булырга тиеш дип ассызыклады. «Кулларына корал тотып, Россия мәнфәгатьләрен яклаучы һәркем өчен шартлар бертөрле булырга тиеш», – диде ул.

Владимир Путин хәрбиләрнең ихтыяҗларына битараф булмаган кешеләргә рәхмәт тә әйтте. «Фронтка балалар гына да 3 млн хат җибәргән! Россия халкы махсус хәрби операция зонасындагы хәрбиләр өчен 10 млрд сумнан артык матди ярдәм җыйган», – диде ул.

Тышкы сәясәт турында

Дәүләт җитәкчесеннән ил эчендә һәм тышкы сәясәттәге төп бурычлар хакында сораштылар. Президент сүзләренчә, төп бурыч – суверенитетны тәэмин итү.

– Бу хакта күп тапкырлар сөйләдем, кабатлаудан гөнаһ булмас. Россия кебек ил суверенитетсыз яши алмый, иң мөһиме – аны ныгыту. Әмма бу – бик киң төшенчә, – диде Владимир Путин. – Бу – тышкы һәм иҗтимагый суверенитет, безнең сәяси системаның, технологик, икътисадый суверенитетның үсеше. Бу – һәр илнең киләчәгенең нигезе.

Чит илләр, аерым алганда, Европа белән мөнәсәбәтләрне җайлау турында да сорадылар Президенттан. Аның сүзләренчә, бу Россиядән генә тормый.

– Бу мөнәсәбәтләрне без бозмадык. Безне икенче-өченче планга күчерергә тырыштылар, безнең мәнфәгатьләрне санга сукмадылар, – дигән фикердә ул.

АКШ белән мөнәсәбәтләргә килгәндә: «Әлегә моның өчен шартлар юк. АКШта эчке үзгәрешләр булырга тиеш, алар да башкаларны хөрмәт итә башларга тиеш», – диде Президент.

Торак-коммуналь хуҗалык турында

«Гыйнварда пенсияләр 7,5 процентка артса да, киләсе җәйдә коммуналь хезмәтләр өчен бәяләр ныграк кыйммәтләнәчәк», – диделәр Илбашына. Җавап йөзеннән Владимир Путин әлеге мәсьәләне тагын бер кат карап тикшерергә сүз бирде. Пенсия күләме арту инфляция дәрәҗәсеннән түбән булмаячагына да ышаныч белдерде ул. Президент искәрткәнчә, соңгы бер ел эчендә пенсияләр ике тапкыр индексацияләнде һәм алга таба тагын артачак. ТКХ тарифлары исә 2022 елдан, ягъни ел ярымнан бирле үзгәрешсез.

Владимир Путин урында ук бер мәсьәләне дә хәл итте.

– Коммуналь хезмәтләр өчен түләгәндә банкларның комиссия алуы дөрес түгел. Бигрәк тә пенсионерларга кагылганда, – диде ул. – Карар хәзер кабул ителде: пенсионерлар комиссия түләмәячәк.

М12 юлы турында

Илбашына киләсе атнада ачылырга тиешле М12 югары тизлекле юлыннан йөрү бәясе артык кыйммәт булудан зарландылар. Әйтүләренчә, яңа юлның бер чакрымы уртача 7 сум тора, Мәскәү – Казан арасы исә якынча 6 мең сумга төшәчәк.

– Миңа билгеле булган мәгълүматларга караганда, ике шәһәр арасы 4–4,5 мең сум торырга тиеш, – диде Владимир Путин. – Минем 6 мең сум турында ишеткәнем юк. Бәлки, юлның һәр өлешендә дә бәяләр бер үк түгелдер. Моны тикшерәчәкмен. Әлеге мәсьәләдә коры арифметика белән генә исәп-хисап ясарга ярамый дип саныйм.

Президент әйтүенчә, юл төзүчеләр гадәттә финанс яктан артык авырлык салмаска тырыша. «Шул ук Казанда, мәсәлән, көньяктарак күпер төзиләр. Елга аша паром 300 сум тора, ә яңа күпердән узу 260–270 сум тәшкил итәчәк», – диде ул.

Гаиләләрне кайгырту турында

«Илдә абортларны ник тыймакчылар?» – дип тә кызыксындылар Владимир Путиннан.

– Бүген мондый тыю юк, – диде ул. – Гомумән, тыюлар турында сөйләшкәндә, үз заманында алкоголь кампаниясе нинди нәтиҗәгә китергәнен күрдек бит инде. Илдә суррогат алкоголь эчүчеләр, көмешкә агызучылар саны күбәйде, үлем-китемнәр артты. Йөклелек чорын өзүгә килгәндә дә шул ук хәл булачак. Әлеге мәсьәләдә гыйбадәтханәләрнең тоткан роле аңлашыла, әлбәттә. Алар һәр гомер өчен көрәшә. Җәмгыятьтә исә хатын-кызларның ирекләре һәм хокуклары саклана.

Илбашы әйтүенчә, дәүләт тә хатын-кызларның үз баласын саклап калуы яклы, әлбәттә. Чөнки илдә демография проблемасы бар. Ничек кенә булмасын, мәсьәләне һәрьяклап хәл итәргә тырышырга кирәк, диде. «Шул исәптән хатын-кызлар консультацияләре, төбәкләрдәге бала тудыру йортлары, сырхауханәләрдә тәртип урнаштыру зарур», – диде Илбашы.

Гаиләләрне кайгырту турында сөйләгәндә, илдә 1 июльгә кадәр гамәлдә булган ташламалы ипотека программасын да озайтырга кирәклеген әйтте.

Йомырка бәясе турында

Тавык йомыркасына бәя арту ихтыяҗ артуга бәйле. Әмма бу хакимияттәгеләрнең җаваплылыгын киметми. Владимир Путин бу хилафлык өчен халыктан гафу да үтенде. "Бу – хөкүмәт эшендәге уңышсызлык», – диде ул.

Путин йомырка, тавык ите бәясе арту турында илнең авыл хуҗалыгы министры белән сөйләшүе турында да әйтте. «Барысы да яхшы, диделәр. Ә мин проблемалар барлыгын әйттем», – диде ул.

Төрлесеннән

Форсаттан файдаланып, Владимир Путиннан: «Ике тамчы судай охшаган кешеләрегез күпме?» – дип тә сорадылар. Юк икән. 8 яшьлек Аринаны тынычландырып: «Бернинди ясалма акыл да әби-бабайларыбызны алмаштыра алмаячак», – диде Илбашы. Кечкенә вакытта ул үзе разведчик булырга хыялланган. «Теләгемә ирештем дә», – дип җавап бирде Владимир Путин. Яңа ел бәйрәмнәрен туганнары һәм якыннары янәшәсендә үткәрергә теләвен әйтте. Ә Президент өчен иң зур бүләк – балалар һәм оныклар. Соңгы сорау: «2000 елдагы Владимир Путинга нәрсә дип әйтер идегез?» – диделәр аңа. Президент озак уйлап тормастан: «Дөрес юлдан барасың, иптәш!» – диде.

Эльвира ВӘЛИЕВА,
Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Ил икътисады – саннарда

➤Ел йомгаклары буенча эчке тулай продукт – **3,5 процент**ка, реаль хезмәт хаклары – **8**, россиялеләрнең реаль керемнәре якынча **5 процент**ка артачак.

➤Эшсезлек **2,9 процент**ка кадәр кимегән.

➤Тышкы дәүләт бурычы – **46 млрд доллар**дан **32 млрд доллар**га, шәхси дәүләт бурычы **337 млрд доллар**дан **297 млрд доллар**га калган.

➤Инфляция – **7,5–8 процент** (ел азагына).

һӘРКЕМГӘ УЯУ БУЛАСЫ

Татарстан юлларында фаҗигаләр, аларда вафат булучылар саны кими бара. Әмма юл сагында торучылар, тынычланырга ярамый, дип кисәтә. Ник дигәндә, саннар алдагы ел белән чагыштырганда кимрәк булса да, хәвефле статистика әле дә булса теркәлә тора. Ә аларның һәркайсы артында кеше гомере ята! Хөкүмәт Йортында юл һәлакәте иминлегенә багышланган утырышта шул хакта сөйләштеләр. Анда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Үч иткәндәй, утырыш үзе үк шомлы хәбәрдән башланды. Иртә белән Шәле – Саескан Тавы юлының 34 нче чакрымында берьюлы 5 машина бәрелешкән иде. Анда өч кешенең гомере өзелде. Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгы башлыгы Артем Хохорин сүзләренә караганда, ел башыннан бирле республикада 3076 юл фаҗигасе килеп чыккан. Анда 258 кеше һәлак булган, 3674 кеше имгәнгән. Үлүчеләрнең 16сы – балалар. Бу саннарның һәркайсы алдагы ел белән чагыштырганда кимрәк. Әмма министр, тынычланырга иртәрәк, дип кисәтте. Ник дигәндә, республиканың кайбер районнарында юлдагы фаҗигаләр дә, аларда үлүче, имгәнүчеләр саны да арткан.

– Актаныш, Биектау, Яшел Үзән, Лениногорск, Менделеевск, Спас районнарында шундый хәл күзәтелә. Димәк, профилактика эше җитеп бетми. Моның өчен киләсе елга каршы як полосага чыгу, җәяүлеләрне бәрдерү, исерек килеш рульгә утыручылар белән көрәшкә игътибарны арттырырга кирәк, – дип белдерде Хохорин.

Менделеевск районы башлыгы Радмир Беляев хәвефле саннарның ни сәбәпле артуын төгәл генә аңлатып бирә алмады. Әмма юл һәлакәтләрен булдырмау юнәлешендә эш көчәячәк, дип ышандырды.

Татарстан Дәүләт автоинспекциясе идарәсе башлыгы Рөстәм Гарипов сүзләренә караганда, быел теркәлгән юл фаҗигаләренең күбесе машиналарның каршы якка чыгуы аркасында килеп чыга.

Ел башыннан бирле республика юлларында 13 мең исерек машина йөртүчегә беркетмә төзелгән. Күбесенең эзенә «Телеграм»дагы махсус төркем аша төшкәннәр. Билгеле булганча, бүген Татарстан Дәүләт автоинспекциясенең «Телеграм»да махсус төркеме бар. Анда исерек машина йөртүчеләр турында хәбәр итәргә мөмкин. Рөстәм Гарипов юллардагы иминлеккә багышланган утырыш саен моның әләкләү түгел, ә кеше гомерен саклау нияте икәнлеген искәртә килә.

tatarstan.ru

Юлда һәркемнән уяулык сорала анысы. Ел башыннан бирле республикада электросамокат, гироскутерда җилдерергә яратучылар катнашында 43 юл һәлакәте теркәлгән. Шул вакыт аралыгында республика юлларында 67 җәяүленең гомере өзелгән.

Юлдагы хәлләр борчуга салса да, гомумән алганда, республикада юл һәлакәтләре саны елдан-ел кими бара *(таблицада)*. Бу урында Рөстәм Миңнеханов юлдагы иминлек сагында торучыларны мактап та алды.

– Эзлекле рәвештә алып барылган чаралар ярдәмендә республика юлларындагы фаҗигаләр санын киметә алдык. Моның өчен ЮХИДИ хезмәткәрләренә, районнардагы юл куркынычсызлыгы буенча комиссия вәкилләренә рәхмәт әйтәсем килә. Юл һәлакәтләре саны арткан районнар исә шуны аңласын иде: фаҗигаләр саны арткан икән, димәк, алар эшне җиренә җиткереп башкарып бетермиләр, – диде Рәис. – Юлдагы аергыч полосаларны тагын кайларга куя алабыз? Шуны төгәл ачыкларга кирәк. Алар барыннан да бигрәк юл һәлакәтләре еш була торган урыннарда булырга тиеш. Юлларда күпме җәяүле гомере дә өзелә бит! Бу ике мәсьәләгә аерым игътибар бирергә кирәк.

Рөстәм Миңнеханов юлдагы иминлекне пилотсыз очкычлар ярдәмендә дә контрольдә тотарга кирәклеген искәртте. Рәис юлларда балаларның һәлак булуына да борчылуын белдерде.

– Балаларга юлда куркынычсызлык кагыйдәләрен өйрәтергә, үзебезгә дә аларга яхшы үрнәк күрсәтергә кирәк. Машина йөртү культурасы, җәяүлеләр культурасы бездә әлегә җитәрлек түгел, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Рәис юлларда самокатта, мотоциклда йөрү тәртибен җайга салырга кирәклеген дә искәртте.

– Мин мотоциклларга каршы түгел. Әмма аны йөртүчеләр еш кына тавыш режимын, башка кагыйдәләрне үтәми. Моңа каршы көрәшергә кирәк, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Рөстәм Миңнеханов, сүзен йомгаклап, бүген юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча зур эш алып барылуын, тулаем алганда, вазгыятьнең яхшырак баруын искәртте.

– Без көн саен юл-транспорт һәлакәтләре турында сөйләшәбез. Хәлне контрольдә тотарга кирәк, – диде Рәис.

Юллардагы вазгыять – саннарда

Ел	Фаҗига	Үлүчеләр	Имгәнүчеләр
2013	5410	709	7032
2017	4690	379	5698
2022	3353	306	4145
2023 (11 ай)	3076	250	3674

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Парламентта

Килешү яңарды

Казанда Татарстан һәм Санкт-Петербург парламентлары арасында килешү имзаланды. Документны Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин һәм Санкт-Петербургның Закон чыгару Җыены Рәисе Александр Бельский имзалады.

Ике арада беренче килешү 2010 елда имзаланган иде. Фәрит Мөхәммәтшин әйтүенчә, ул документны, бүгенге шартларны исәпкә алып, яңартырга вакыт җиткән иде. Аның сүзләренә караганда, комитетлар, фракцияләр һәм депутат төркемнәре арасында хезмәттәшлекне киңәйтергә кирәк. «Ике парламентта да уртаклашырлык тәҗрибә бар», – диде ул.

Килешү имзалау тантанасы алдыннан Дәүләт Советы Рәисе Санкт-Петербургның Закон чыгару Җыены депутатлары белән очрашты. Төньяк башкала делегациясе Казанда Татарстанның Инвестицион үсеш агентлыгында булдылар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, Ленинград блокадасын кичергән кешеләр белән очраштылар. Моннан тыш, Иннополисны барып күрергә, тарихи урыннар белән танышырга ниятлиләр.

Дәүләт Советы депутатлары игътибарына

Алтынчы чакырылыш Татарстан Дәүләт Советының илленче утырышы дүшәмбе – 18 декабрьдә (10.00 сәгатьтә башлана) Дәүләт Советы утырышлар залында үткәрелә.

Депутатлар Дәүләт Советы бинасында 18 декабрьдә 8.00 сәгатьтән башлап теркәлә.

Белешмәләр алу өчен телефон: 267-63-62.

Көч һәм горурлык

Татарстан республикабызны данлаган спортчылар һәм тренерлар белән горурлана. Спорт сезонына йомгак ясалган тантанада Татарстан Рәисе шулай дип белдерде. Чараны физик культура һәм спорт өлкәсендә дәүләт идарә органы оешуның 100 еллыгына багышлап уздырдылар.

Рөстәм Миңнеханов үз чыгышында ТАССРда физик культура һәм спорт өлкәсендә идарә органының беренче җитәкчесе – Физик культура Югары Советы рәисе Хәмит Сафинны, бу өлкә белән катлаулы елларда җитәкчелек иткән Хәниф Мортазинны искә алды. Спорт тармагында министр булып Марат Бариев эшләгән елларда зур үзгәрешләр булды. Аның тәкъдиме һәм Беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиевнең хәер-фатыйхасы белән 2013 елда Казанда Универсиада узды. «Студентларның Җәйге Уеннары башкалабызның йөзен үзгәртте һәм спортның үсеше өчен зур мирас калдырды», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Рәисе республиканың иң танылган спортчылары, командалары, аларга ярдәм итүче тренерлар, федерацияләр, иганәчеләргә, спортчыларның якыннарына рәхмәт әйтте. Аның сүзләренә караганда, бүген республикада физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен мөмкин кадәр уңайлы шартлар булдыру буенча зур эш алып барыла. Заманча спорт объектлары төзелә, спорт мәктәпләренең матди-техник базасы ныгытыла, спортчыларга һәм тармак хезмәткәрләренә ирешкән нәтиҗәләре өчен ярдәм күрсәтелә. «Тармакны үстерүгә киткән акчаның сәламәт буынны тәрбияләү өчен тотылган нәтиҗәле чыгым булуына шикләнмим. Татарстан халкының 60 проценты системалы рәвештә физкультура һәм спорт белән шөгыльләнә. Планлы эш нәтиҗәсе бу», – диде Рөстәм Миңнеханов.

Киләсе елда Казанда Киләчәк Уеннары һәм БРИКС илләренең спорт уеннары узачак. «Аларның республика һәм ил тарихында зур эз калдырасына, ә башкалага килгән катнашучылар һәм кунакларның онытылмаслык хисләр алып китәсенә ышанам», – диде Татарстан Рәисе.

Тантанада 2023 елның иң яшь спортчыларын игълан иттеләр. Олимпия төрләре буенча «Ел спортчысы» дип **Даниел Маринов** (спорт гимнастикасы) һәм **Софья Дьякова** (йөзү) танылдылар. Олимпия Уеннары программасына кермәгән төрләрдә иң яхшылар булып самбо буенча дөнья чемпионы **Ксения Задворнова** һәм билбаулы көрәш буенча дөнья чемпионы **Илнар Закиров** танылдылар. Мөмкинлекләре чикле спортчылар арасында **Анастасия Огнева** (спринтер) һәм **Иван Пакинны** (озынлыкка сикерү) бүләкләделәр.

Язучы сүзе

Көннәр салкын...

Кеше күп нәрсәләрне аңлап җиткерә алмый инде ул. Моны барыбыз да беләбез. Шуны аклау өчен мең сәбәпләр табып бетерәбез. Вакытыбыз юк, аның хәстәре түгел, миңа нигә кирәк ул, галимнәр баш ватсын һәм тагын әллә нәрсәләр. Чыны да шулай аның, без аңламый торган нәрсәләрнең бик күбесе безгә кирәкми, кагылмый, тормышыбызга бернинди дә йогынты ясамый. Ләкин без үзебезгә турыдан-туры кагылганнарын да бик төшенеп җитмибез.

Теләмибез дә бугай. Күз алдына китерү өчен шундый мисал менә: без кемнеңдер күзенә карый-карый киләбез дә аны күрмичә үтеп китәбез. «Әй, кайда син, югалдың?» – дип сөрәнләргә дә мөмкинбез әле. Һәм шул көебезгә, барысын да аңлаган, барысын да белгән кыяфәт чыгарып яши бирәбез.

Әле менә көннәр салкынайды. Урамда – минус кырык биш градус. Көн кыска. Эшләр күп, тик бернигә дә өлгереп булмый. Күңелдә канәгатьсезлек. Үземнең булдыксызлыгымны да яратмыйм, һава торышын да. Иң ашыккан чакта көн кыскара. Иң өшегән чакта салкынайта. Тормыш гел кешегә аркылы төшәдер кебек тоела. Күңелсез шулай булгач.

Бер карасаң, безнең тормыш гел шулай бит ул. Өй эчендә сабый йоклый менә. Аяк очларына басып кына, бер тавыш-тын чыгармаска тырышып йөрисең. Кинәт син бөтенләй искә-сангә алмаган нәрсә дөбер-шатыр килеп авып төшә. Шауламаска тырышкан саен ныграк тавышланасың. Кемнеңдер килүен көтәсең, аны тының белән суырып алырдай булып, тәкатсез булып көтәсең. Нәкъ менә шунда вакыт агышы акрынаеп кала. Үзәнлеккә чыккан елга сыман талгыная. Ә син ашыгасың. Кабаланасың. Вакытның исе дә китми. Әллә күпме мисаллар китерергә була инде. Шуларны уйласаң, тормыш безгә гел каршыдыр сыман тоела башлый.

Тик алай түгел бугай ул. Без тормышны бик үк дөрес аңламыйбыз гына бугай. Менә шул һава торышын гына алсаң да... Салкын инде. Булса соң! Өеңдә җылы бит. Ят шунда. Димәк, тормыш сиңа бар мәшәкатьләреңне дә онытып, өеңдә утырырга яки юрган астына кереп посарга, ял итәргә куша. Үз ихтыярың белән шулай ял итә белмисең бит. Каядыр омтылган буласың, нәрсәдер майтарырга маташасың. Тынгысызланасың. Ә табигать сиңа беркадәр тукталып торырга тәкъдим ясый. Онып мәшәкатьләреңне, ял итеп ал беразга, ди. Шуның өчен бөтен шартлар тудыра. Законный шартлар. Беркем сине гаепли алмый, «Ник шуны эшләмисең?» – дип тирги алмый. Өстәвенә ул көннәрне дә кыскарткан. Димәк, аның сине эшләтәсе килми. Бу бит инде фәлән хакка путевка алып, курортка озату сыман. Кышларын салкынайтса, җәйләрен ул, коеп, яңгыр бирә. Яки көннәрне чамасыз эссе итә: «Ят күләгәдә рәхәтләнеп», – ди, әлсерәп йөрмәскә куша. Нәрсәне генә мисалга китерсәң дә, табигать күренешләре, тормыш үзе безгә иң кирәкле шартлар тудыра.

Тик без генә аңлап җиткермибез. Без соңгы көнебезне яшәгән сыман чатнама суыкларда, салкын яңгырларда, көйдергеч эсселәрдә нәрсәдер эшләргә тырышып йөрибез. Нәкъ бүген, нәкъ шушы мизгелдә артыбызны катырып, күшеккән тавык хәлнә калып, яки эсседән телебезне аркылы тешләп, нәкъ шушы эшләрне эшләмәсәк, дөньяның берәр җире кителеп төшәр шикелле тоела. Әти-әниләренең: «Башыңа ки, балам... Аягыңа ки... Саулыгыңны сакла, картайгач искә төшә ул...» – диюенә игътибар итмичә, яланбаш чыгып киткән балалар кебек.

Ә дөньяның бер җире дә кителми. Безнең нәрсәләрдер эшләргә маташудан гына артмый да, кимеми дә ул. Чөнки эшләргә маташу – эшләү түгел әле ул. Ә безнең, үзсүзләнеп, нәрсәдер маташтыру беркайчан да юньле нәтиҗә бирми: эшең дә килеп чыкмый, ял да итә алмыйсың. Бары тик шул гына.

Бу тормышта барысы да гади генә бугай: ял итәргә мөмкинлек булганда, һәрчак ял итәргә кирәк, эшләргә ихтыяҗ туганда – эшләргә. Шулай уйлагач, салкынның озаккарак сузылуын тели башладым әле. Һава торышыннан тормый бернәрсә дә, барысы да безнең уйдан тора.

Марат КӘБИРОВ

ИКМӘК ҺӘМ ИНФЛЯЦИЯ

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Газета укучылар, бәлки, хәтерли торгандыр: җәй төгәлләнеп, көзгә аяк басарга җыенганда, мәгълүмат кырында, ипи бәясе ун процентка күтәреләчәк, дигән хәбәр таралды. Рәсми даирәләр моны шунда ук кире какты: булмас, диделәр. Дәлил ышанычлырак булсын өчен, рус телле «Forbes»тан тәрҗемәсез генә цитата китерик: «Минсельхоз заявил, что информация «не имеет ничего общего с действительностью» и что динамика цен на хлеб в 2023 году не превысит уровень общей инфляции». Җәй ахырында ипи бәясе турында «фейк» таратучыларның дәлилләре көчле иде ләкин: санкцияләр, Мәскәүнең «ашлык килешүе»ннән чыгуы, сумның йомшаруы...

Көз үтеп, икмәк үскән кырлар ак юрганга төренде. Рәсми рәвештә зур уңыш җыеп алу хакында рапорт күренде: быел россиякүләм 151 миллион тонна ашлык суктырылып, амбарларга салынган. Планета масштабында карасак та, уңыш зур, биржаларда ашлыкка бәяләр төшә. Әммә... «Российская газета» соңгы санында Россия шәһәрләрендә икмәккә бәя күтәрелү турында язма бирә. Мәскәүдә, ди, 2022 елның гыйнварыннан 2023 елның октябренә кадәр ипи бәясе 83 сумнан 101 сумга кадәр үсте. Газета икмәк кыйммәтләнгән төбәкләр арасында Татарстанны да искә ала. Россия буенча икмәк уртача 63 сумнан 73 сумга кадәр күтәрелгән икән. Оппозициядәге икътисадчылар әйткәнгә караганда бераз ныграк та кыйммәтләнгән әле, ун проценттан да артып киткән. Ростов өлкәсенең статистикасы, мәсәлән, 2021 ел белән чагыштырганда икмәкнең кайбер төрләренә бәяләр 45,7 процентка үсүен әйтә.

Ипи – фәкыйрьләр ризыгы, шуңа күрә аның бәясе «тешли». Кара уылдыкка бәя күтәреләме-төшәме – берәүне дә дулкынландырмый, ипи хакы исә социаль тетрәнүләр китереп чыгарырга мөмкин. Шуңа күрә аның бәясен йөгәнләп торырга тырышалар. Әммә массакүләм кулланылыштагы бу ризыкның бәясе турында сүз барганда, Авыл хуҗалыгы министрлыгы бакчасына таш ату урынсыз. Татарстанда авыл хуҗалыгында эшләүчеләрнең уртача хезмәт хакына күз салыйк әле. Республика буенча ул 45585 сумга тәңгәл. Күрсәткече 28–29 мең сумны гына тәшкил иткән районнар да бар. Ә республикадагы уртача хезмәт хакы быелның июнь аенда 62 мең сумнан артык. Килешәсездер: аерма сизелерлек. Авыл хуҗалыгында эшләүчеләр дә ипине сатып ала. Кыйммәткәрәк тә алалар әле. Авылда эшче куллар кытлыгы булмасын дисәк, хезмәт хакын шәһәрдәгедән югарырак итәргә кирәк булыр иде... Ләкин мәсьәләнең иң аянычлы ягы шунда: ашлыкка бәя үсмәде диярлек, кимеде дә әле. Быелның августында җитештерүчеләрдә бодайның тоннасы 150 доллар булган, ә 2022 елда – 280 доллар. Дөрес, ноябрь – декабрьгә бодай бәясе 30–40 процентка кыйммәтләнер дип фаразлаганнар җәй көне. Кыйммәтләнгәч тә үткән елдагыдан арзанрак чыга барыбер.

«Икмәк ник кыйммәтләнә соң?» – дигән сорауның җавабы шуңа күрә катлаулырак. Ипи бәясендәге ашлык өлеше 12–23 проценттан артмый, ди Россия ашлык союзы президенты Аркадий Злочевский. «Российская газета» да раслый моны: «В булке хлеба затраты на пшеницу (муку) составляют не более 15 процентов от ее общей себестоимости», – дип яза. Димәк, бәя күтәрелүнең сәбәбе бөтенләй башкада. Ипигә бәя тотрыклы булсын өчен, иң беренче адым аның бәясендәге ашлык өлешен 50–60 процентка җиткерү булыр иде. Укучыга бу парадокс булып тоела торгандыр, әмма икмәк бәясен күтәрмичә дә бу пропорциягә ирешеп була. Әйтик, салымнар өлеше ашлык өлешеннән дә зуррак. Ипи бәясенә турыдан-туры салымнар гына түгел, әйтик, ягулык салымнары да үз өлешен кертә. Бензин бәясендә салым өлеше 80 процентка җитә, диләр. Ягулык бәясе бар товарларга да бәяне ярыйсы ук өсти...

Гомум инфляция дигән нәрсә бар бит әле. Акча очсызлана икән, бәяләр котылгысыз рәвештә үсә. Үзәк банк төп ставканы күпме генә күтәрмәсен, бәяләр тукталмаячак. Бәя үсешен бер генә юл белән туктатып була: акча басуны туктатасың. Үзәк банк коммерция банкларына акчаны каян алып бирә? Табышыннан, диярсез инде. Чынлап та, процентлы кредит биргәч, Үзәк банкка арттырып түлиләр. Шул артыклык табыш булырга тиеш. Процентны никадәр күтәрсәң, табыш шуның кадәр зуррак булачак һәм Үзәк банк күбрәк кредит бирә алачак. Әйдәгез, Үзәк банкның 2022 елга отчетын карыйк әле. «Россия банкы, – дип хәбәр итә «Интерфакс», – 2022 елда 721,7 миллиард сумлык зыян күрде, бу 2021 елгы зыяннан 27 тапкыр күбрәк». «Шуның кадәр акча югалткач, Үзәк банк, акчаны каян алып, кредит бирә?» – дигән сорауны тагын бер кабатлыйк. Җавабы гади генә: акча станогын эшләтә. Илдә акча күләме арткач, аның бәясе төшми кала алмый инде. Базарның төп законнарының берсе бит бу: нәрсә күп, шуңа бәя төшә. Акчаның бәясе төшәчәген һәркем алдан белеп тора, шуңа күрә аны күпме генә процент белән бирмәсеннәр, күбрәк алып калырга тырыша. Бәясе төшә торган акчаны чиновниклар ил икътисады өчен мөһим дип саналган тармакларга юнәлтәләр. Авыл хуҗалыгы андый тармаклар хисабына керми. Субсидияләнә ул, сүз дә юк. Кредитлар белән дә күмәләр, әммә, бердән, масштаблар бүтән, икенчедән, авыл хуҗалыгы продукциясенә бәя күтәрелсә, аны административ рәвештә тотып торырга тырышалар. Йомырка бәясенә Генпрокуратура катнаша башлый. Бәясен ясалма рәвештә тотып торалар икән, ул тармакка үз иреге белән инвестицияләр ясамый берәү дә. Тавык фабрикалары һәм алардагы тавыклар саны кими, әйтик. Саннарны китереп тормыйк, чынлап та, Россиядә кош-корт һәм терлекләр саны коточкыч темплар белән кими. Я дефицит, я бәя күтәрелү дигән ике юлның берсе кала. Прокурор санкцияләре беренче юлга илтә.

Боларның барысын да бер формулага җыеп була: кешеләрнең Аллаһ каршындагы бәясе төшсә, товар бәяләре үсә. Риба (процент капиталы) – Аллаһ тарафыннан катгый тыелган җиде зур гөнаһның берсе. Тыелган нәрсә белән массакүләм һәм ачыктан-ачык шөгыльләнеп, кешеләр Хак Тәгалә каршында үз бәяләрен төшерә. Шулай булгач, ипигә бәя ник күтәрелмәсен? Бәяләр күтәрелүнең котылгысызлыгын автор менә шулай аңлый һәм аңлата да.

shutterstock.com

Эльвира ВӘЛИЕВА

САБЫРСЫЗ ТОРАК

Киләсе елда тораклы булырга теләүчеләргә акчаны тагын да күбрәк җыярга туры киләчәк. Ил Хөкүмәте ташламалы ипотека буенча беренчел кертем күләмен 20дән 30 процентка кадәр күтәрмәкче. Түбә булмаса да кыен, булса да. Татарстанда фатир хуҗаларының банкларга ипотека буенча 540 миллиард сум (!) бурычы бар. Бәяләр исә үсүдән туктарга җыенмый. Республиканың төзелеш тармагы быел нәрсәләр белән истә калды? 2024 елда торак базарын ни көтә? Бу хакта белгечләрдән сорадык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Быел республикада 3 миллион 100 меңнән артык квадрат метр торак төзелгән.

Коткылы август

Зәлия һәм Рамил Миңнуллиннар Казанга Чаллыдан җәй башында күченеп килгән.

– Әлегә туганнарның фатирында торабыз, узебезнекендә – ремонт, – ди гаилә башлыгы. – Казанга күченгәч тә, сатып алырга дип торак эзли башладык. Баштарак, фатирларны иске йортлардан карадык. Әшкә дә, балалар укыган мәктәпкә дә якын булсын, янәсе. Тик без сайланган арада икенчел торак базарында бәяләр кул җитмәс булып кыйммәтләнде. Ахыр чиктә, шәһәрдән читтәрәк, Лаеш районының Усады бистәсендәге «Южный парк» торак комплексында ике бүлмәле фатир сатып алдык. Утыз ел гаилә ипотекасы буенча ай саен 33 мең сум акча түләргә туры киләчәк. Торакны шәһәр эчендә сатып алам дисәң, айлык түләү ике тапкыр кыйммәтрәк.

Билгеле булганча, җәй азагында торак базарында сату-алулар кискен артты. Сәбәпләре дә билгеле: Росия Үзәк банкы августта төп ставканы 8,5тән – 12 процентка, сентябрьдә – 13, көз ахырында 15 процентка кадәр күтәрде, ташламалы ипотека буенча беренчел кертемне 15тән 20 процентка кадәр җиткерделәр. Өстәвенә сум да тотрыксыз.

– Болар барысы да август аенда торак базарының бик нык җанлануына китерде, – ди икътисад белгече Илдус Сафиуллин. – Аңлашыла ки, гади халык кесәдәге акчасын югалтмас өчен, аны эшкә җигеп калырга ашыкты. Сорау арткач, торакка бәя дә үсте. Үзегез уйлап карагыз: узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, Казанда яңа йортлардагы фатир бәяләре уртача 1–1,5 миллион сумга кыйммәтләнде.

– Чаллыда яңа йортлардагы фатирның бер квадрат метры – уртача 110 мең сум. Өч ел элек кенә ул 30–40 мең сумга арзанрак иде, – ди автокалада риэлтор булып эшләүче Марат Газизов. – Түбән Камада да торакка сорау сизелерлек артты. Биредә яңа түбәнең бер квадрат метры – 80–100 мең сум тирәсе тәшкил итә.

Биш ел кирәк

Алга таба вазгыять үзгәрмәгәе: сентябрьдә ташламалы ипотека буенча беренчел кертем күләмен 15тән 20 процентка кадәр күтәрделәр. Бу көннәрдә Россия вице-премьеры Марат Хөснуллин ил Хөкүмәтендә аны 30 процентка кадәр күтәрү мәсьәләсе тикшерелүен дә хәбәр итте.

Сер түгел, илдә яңа торакның 80–90 проценты ташламалы ипотека программалары ярдәмендә үз хуҗасын таба. Икенчел торак базарында әлеге күрсәткеч иллегә – илле чамасы, ди белгечләр. Халык арасында иң зур кызыксыну уятканы – яңа йортлардагы фатирларга 8 процентлы ташламалы ипотекадыр, мөгаен. Ул киләсе елның 1 июленә кадәр гамәлдә. Гаилә ипотекасының процент ставкасы – 6 процент. Моннан тыш, Ерак Көнчыгыш ипотекасы – 2, IT тармакта эшләүчеләрнеке 5 процент тәшкил итә. Ә менә авыл ипотекасына килгәндә, Үзәк банк төп ставканы күтәрү турында карар кабул иткәннән соң, 0,1–3 процентлы әлеге программаны вакытлыча туктатып торырга да туры килде.

Ул арада Россия Президенты Владимир Путин төбәкләрдә ташламалы ипотека буенча кредит күләмен арттыруны хуплады. Хәтерләсәгез, әлеге тәкъдимне Мәскәүдә узган киңәшмәләрнең берсендә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов әйткән иде.

Аның сүзләренә караганда, яңа торак базарыннан фатир сатып алучыларга нәкъ менә ташламалы ипотека программалары ярдәм итә. «Бүген Казанда ике бүлмәле фатирның уртача бәясе 12–13 миллион сум тора. Балалы гаиләләр арасында әнә шундый торакка ихтыяҗ зуррак», – дип тә өстәде ул. Татарстан Рәисе гаилә һәм ташламалы ипотека программалары буенча иң зур кредит күләмен хәзерге 6 миллионнан 12 миллион сумга кадәр күтәрергә тәкъдим итте. Рәис фикеренчә, тегe яки бу ташламалы ипотеканың тәмамлану вакыты җиткән саен, халык арасында торакка сорау кискен арта. Шуңа күрә дә, мөмкинлекләр булганда, ташламалы ипотека программаларын вакыт ягыннан да чикләмәскә тәкъдим итте ул.

Ә түбәле булырга теләүчеләргә акча җыясы гына кала. Моның өчен күпме вакыт кирәк икәне дә билгеле. «РИА Новости» белгечләре илдә яшәүче өч кешелек гаиләгә 60 квадрат метрлы фатир сатып алу өчен беренчел кертемгә ничә ел акча тупларга кирәк булуын исәпләп чыгарган. Татарстан әлеге рейтингта – 24 нче урында. Республикада яшәүче урта хәлле гаиләгә моның өчен аз да түгел, күп тә түгел – 4,8 ел вакыт кирәк булачак, дигәннәр. Ә татарстанлыларның 20 процентына моның өчен кимендә ун ел итәк-җиңнәрне җыясы. Һәр бишенче гаилә дигән сүз бу!

«Сату-алулар кимеячәк»

Саннардан күренгәнчә, Казанда иске йортта фатирның бер квадрат метры уртача 130 мең сум тора. Яңа төзелгән торакка караганда, арзанрак, әлбәттә. Әмма кешедән калган түбәне сатып алырга теләүчеләргә ташламалы программалар юк. Кредит оешмалары исә Үзәк банк артыннан ипотека ставкаларын да күтәрә. «ВТ» хәбәрчесе исәпләп тә карады: Казанның Идел буе районында 1990 нчы елларда төзелгән йортта бер бүлмәле фатирны 5 миллион сумга табарга мөмкин. Кулда 1 миллион сум акча бар, ди. Банк бурычка акчаны 16–17 процент белән бирә. 25 һәм аннан да күбрәк елга ипотека рәсмиләштергән очракта, айлык түләү 57–65 мең сум тәшкил итәчәк.

Халыкның ни өчен яңа фатирларга өстенлек бирүе аңлашыла, ди Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече Фәнис Хөсәенов.

– Илдә өч елдан бирле яңа төзелүче йорттагы фатирларга ташламалы ипотека программасы гамәлдә. Аның буенча айлык түләү иске йорттагы фатирныкына караганда очсызрак килеп чыга, – ди ул. – Хәер, Үзәк банк төп ставканы күтәргәч, икенчел торак базары да җанланды. Чөнки моңа кадәр милек базарында вазгыять яхшырганны көтүчеләр дә, алга таба ипотека тагын да кыйммәтләнүдән куркып, фатир сатып ала башлады. Минем уйлавымча, алга таба милек базарында сату-алулар саны кимеячәк. Чөнки бүгенге шартларда фатир сатып алырга әзер булучылар күп калмады. Өстәвенә Үзәк банк 1 сентябрьдән кредит бирүгә бәйле таләпләрне катгыйлатты. Йорт яки фатир сатып алучылар, беренчел кертемгә акча булмаганлыктан, куллану кредиты рәсмиләштерүләрен бик яхшы аңлыйбыз бит. Әйе, бүген без номиналь яктан да, реаль яктан да халыкның керем дәрәҗәсе артуын сизәбез. Тик бу икътисадның барлык өлкәләренә дә кагылмый.

Быелның августында Татарстанда фатирларга сорау – 51, Казанда исә 70 процентка артты. Бүген Казанда, мәсәлән, яңа йортларда фатирның бер квадрат метры уртача 196 мең сум тора. Чагыштыру өчен, ел башында әлеге күрсәткеч 174 мең сум чамасы (үсеш – 12–15%) тәшкил иткән.

Татарстанда яшәүчеләрнең банкларга 955,7 миллиард сум бурычы бар. Шуның 539,7 миллиард сумы ипотекага туры килә. Быелның ун аенда гына да республикада 108 меңнән артык ипотека килешүе төзелгән. Үзәк банк мәгълүматларына караганда, бу елның сентябрендә Татарстанда яшәүчеләр кредит оешмасыннан бурычны уртача 25 ел да 5 айга рәсмиләштергән. Бу – рекорд күрсәткеч. Чагыштыру өчен: былтыр ипотеканы күп дигәндә 23 ел да 8 айга алганнар.

Фикер

Марат АЙЗАТУЛЛИН, Татарстанның төзелеш, архитектура һәм ТКХ министры:

– 2022 ел белән чагыштырганда, быел Татарстанда төзелеш эшләре күләме 20 процентка артып, 685 миллиард сум тәшкил итәчәк. Торак төзелеше даими үсештә. Бу өлкәдә иженче ел рәттән үзебез үк куйган рекордларны яңартабыз. 2021 елда республикада кулланышка тапшырылган торак күрсәткече буенча тәүге тапкыр 3 миллион квадрат метр чикне уздык. Былтыр 3 миллион 93 мең квадрат метр торак кулланышка тапшырылды. Быел исә 3 миллион 100 мең квадрат метр торак төзү каралган иде. Татарстан төзүчеләре тизрәк тә эшләде. 9 декабрьгә алынган мәгълүматларга караганда, республикада 3 миллион 186 мең квадрат метр торак төзелгән. Аның 1,6 миллионы – шәхси йортларга, 1,3 миллионы – күпфатирлы торакка, 147 мең квадрат метры социаль ипотекага туры килә. Ел төгәлләнмәгән әле. Шуңа күрә узып баручы елга йомгак ясарга иртәрәк. Ил Хөкүмәте тарафыннан куелган бурыч нигезендә, 2030 елга без ел саен 3,5 миллион квадрат метр торак төзүгә омтылабыз. Әлеге эш инженер челтәрләрне яңарту һәм социаль инфраструктурага да турыдан-туры бәйле. Исегезгә төшерәм: быел Татарстанда 44 республика программасы гамәлдә. Алар киләсе елда да дәвам иттереләчәк. Шулай ук 5 дәүләт программасы һәм 7 илкүләм проект кысасында проектлар тормышка ашырылды. Гомумән алганда, сүз 126 миллиард сумлык 4 меңнән артык объект турында бара.

Ләйсән САФИНА

ТЫНГЫСЫЗ КАРАШАЙ

Кайткан чакта Сарман буйларына... Кышкы кояшлы көннәрнең берсендә атаклы Илһам Шакиров җырларында җырланган районга юл тоттык. Үз көчләре белән муллыкка ирешеп, авыл тормышын чын күңелдән яратып, хезмәтеннән тәм табып яшиләр биредә. Районда гына түгел, республикада да алдынгылар сафында булган Карашай-Саклау авылы әнә шул ягы белән сокландырды.

Эшле һәм ашлы халык

Авылда тормыш көйләнгән, урамнары киң, йортлары зур, матур. Карашай-Саклау һәм Чураш җирлекләрендә ике авылда 480 кеше яши. Аларда төп белем бирү мәктәбе, мәдәният йортлары, ике ФАП, ике музей, ике китапханә, балалар бакчасы, мәчетләр, кибетләр – кыскасы, яшәү өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Урамнары төзек, асфальт җәелгән. Авылның бүгенге тормышы шулай гөрләп баруда җирлек башлыгы Вероника Хөсниеваның роле зур. Башта 25 ел хисапчы булып эшләгән, башлык вазыйфасына килүенә – тугыз ел.

«Безнең авыл – бердәм организм», – ди җирлек башлыгы Вероника Хөсниева.

– Авылның яшәеше, җитәкчедән бигрәк, күбрәк авылдашлардан тора. Безнең халык бик бердәм. Күңелең ачык булып, бер-береңне аңлап, чын күңелдән сөйләшәсең икән, шул вакытта авыл яши, – ди Вероника ханым.

Карашай-Саклау – шәхси эшмәкәрлек буенча алга киткән, зур үсеш алган авылларның берсе. Эш юк дип, кул кушырып утырмыйлар, үз эшләрен булдырып, көн күрәләр монда. Кемдер терлекчелек буенча мини-ферма булдырган, тимер, агач эше белән шөгыльләнүчеләр күп. Эретеп ябыштыручыларга, йорт төзүче бригадаларга, балта осталарына да бай авыл.

– Авылда күбесенчә безнең буын, безнең яшьтәгеләр калган. Без шуның белән көчле дә. Шулар тота авылны, – ди җирлек башлыгы. – Эшлим дигән кешегә авылда эш җитәрлек. Яшьләр ата-бабаларыннан калган һөнәрләрне дәвам иттерә. Нинди генә тармакны алсак та, эшсез кеше юк. Мөмкинлекләр күп, юллар әйбәт, җитәкчелеккә мең рәхмәт. Шушы көнгә кадәр асфальт кермәгән авыллар бар. Үзебезне алар белән чагыштырып, сөенәсөенә яшибез. Тормышыбыз бик әйбәт.

105 хуҗалыкка – 220 сыер

Кайбер җирлектә урман күп, кайда – ташлык, карьер булса, Карашай-Саклауга табигать байлыкны болын белән биргән. Терлекләрнең баш саны буенча республикада беренче урында алар. Биредә 105 хуҗалыкка – 220 сыер. Кеше саен сыер ярым чыга дигән сүз бу.

– Сарман ягы – болын, кыр ягы. Безнең иң зур өстенлек бу. Бездә кеше күпләп мал тота. Соңгы өч елда биш гаилә фермасы төзелде. 35–50 яшь тирәсендәге гаиләләр 8–10ар сыер асрыйлар. Җәй көне 70–80 мең сум акча керә. Иң куанычлысы – 220 сыерга ел саен 800 мең сум субсидия алабыз, – ди авыл җирлеге башлыгы. – Әгәр безнең 300 гектар болын булмаса, бу кадәр сыер асрап булмас иде. Сыерга күченеп йөрергә иркенлек кирәк. Сүз дә юк, әгәр үзең тырыш булмасаң, 1000 гектар болын булса да, асрамаган кеше асрамый инде ул.

Авыл кешесенең авырткан җире булган сөт бәясе төшүдән дә зарланмый мондагы халык. Чөнки альтернатив юлларын эзләдек, ди Вероника Хөсниева.

– Сөт җыючылар арасында көндәшлек бездә. Быел өчәү җыйдылар. Сарман сөт кооперативы белән килешү төзеп эшләдек. Бөтен республика буенча сөт 15 сумга калган чакта да апрельдән башлап 23 сумнан җыйдык. Бүген сөт бәясе – 26 сум. Без бик канәгать. Бездә хәтта 70 яшьлек әбиләр дә сыер асрый. Алар да асрагач инде, безгә ни хәл? Минем үземнең өч сыер, өч тана. Безнең бәләкәй генә урамнан да 40 сыер чыга көтүгә, – диде ул.

Игезәкләр Гөлфия белән Әлфия Фәхразиевалар – югары белемле тәрбиячеләр. Чаллыда балалар бакчасында эшләгәннәр. Тик аларга яңадан туган нигезләренә кайтып төпләнергә насыйп булган.

Фәхразиевалар алты ел элек, 200 мең сум грант отып, мини ферма булдырганнар. Хәзерге көндә 13 сыер һәм 100ләп баш кош-корт асрыйлар.

– Үзем социаль хезмәткәр булып эшлим. Игезәк сыңарым агрофирмада сыер сава. Абыебыз Нәҗип Себердә вахта ысулы белән эшли. Сыр, сары, ак май, эремчекләр җитештерәбез, – дип сөйләде Гөлфия апа.

Уңган фермер маллар карарга да, матур гөлләр үстерергә дә өлгерә. Әле моның өстенә куяннар, этләр, песиләре дә бар. «Тулы бер зоопарк бездә, шөкер», – ди Гөлфия Фәхразиева, уенын-чынын бергә кушып.

Данлыклы «КамАЗ»чы егетләр

Карашай-Саклау үзенең «КамАЗ»лы егетләре белән дан тота. Биредә ир-атларның күбесе 2000 нче елларда, колхозлар таралгач, үзләренә әнә шул машиналарны сатып алган. Андыйлар бүген авылда 26 кеше икән. «Безнең Карашайның данын күтәрде шушы егетләр», – ди алар турында Вероника Хөсниева.

– Әтидән калган бәләкәй генә «КамАЗ»дан башлаган идек, – ди бу эш белән 12 еллап шөгыльләнүче 38 яшьлек Ирек Вәгыйзов. – Шуңа әкренләп тагылмалар алып, яңартып, авыл хуҗалыгы продукциясе, такта ташыдык. Хәзер чөгендер, такта, мунча, йорт буралары ташыйбыз. Минем белән бертуган энем Алмаз да эшли. Удмуртиягә, Киров якларына барабыз. Шушы бер машина бөтен гаиләне туендыра, Аллаһка шөкер.

Ирек Вәгыйзов хәрби операциядәге егетләргә зур күләмдә гуманитар ярдәм дә оештыра икән.

– Үзебезнең егетләр белән бергә җыелышып эшлибез. Без монда җылыда, ә тегендә егетләр салкын окопта яталар бит. Ничек тә, хәлдән килгәнчә, үз өлешебезне кертәсе килә. Җибәргән саен уртача 80–100 мең сумлык әйбер җыябыз. Күбрәк тә булганы бар, – дип сөйләде ул.

Әби белән әбичә, бәби белән...

Халык белән килешеп, бердәм яшәүнең сере нидә соң? Җирлек башлыгы фикеренчә, иң мөһиме – үзең хыялыйрак булып, үзең шуның эчендә кайнау.

– Әбиләр белән дә, бәбиләр белән дә бер дулкында булырга кирәк. Бездә халык тыңлаучан. Беркайчан да кире какмыйлар. Без – бердәм организм, – ди Вероника Хөсниева.

Үзе таянып эшли торган кагыйдәләре дә бар җирлек башлыгының. Әйтик, үзара салымда кешедән күпме акча кергән, шул акча кире үзенә кайтырга тиеш, дигән фикердә ул. Авылда аны кеше башыннан 600 сумнан җыялар икән.

– Көндәлек эшләрне башкарырга җитә. Быел ФАПка капиталь ремонт ясалды. Авылда быелтыр спорт мәйданчыгы төзелде. Район газетасына, кеше үлгән саен, кайгы уртаклашу бирәбез. Ул бит – минем авылдашым, бергә эшләгән сыер савучы, тракторист, күршем. Ничек мин аның кайгысын уртаклашмыйм ди инде? Юбилярларның һәрберсен котлыйбыз. Өлкәннәр көненә, җыелып, бүләкләр алабыз. Бер бәйрәмне дә калдырмыйбыз. Үзләре монда яшәмәсә дә, әбисе, әнисе шушы авылдан булган балаларга Яңа ел бүләге бирәбез. Бу матур гадәткә егерме еллап бар инде. Мине коллегалар сүгә, син генә йөрисең, диләр. Аларның бит күңеле була. Ник мин аларга акча жәлләим ди? Ә кем белә, бәлки, Аллаһы Тәгаләнең амин дигән сәгатенә туры килеп, ул балалар монда кайтып төпләнер? Элемтәләрне югалтмыйбыз, туган җиргә күренмәс җепләр белән бәйләп торабыз, – ди җирле үзидарә рәисе.

Вероника Хөсниева һәм авылның бик күп уңганнары кебек тынгысызлар авылны яшәтә дә инде.

– Авыл советында эшләү өчен иҗади кеше булырга кирәк. Безнең бөтенебез шулай. Һәрбер кешенең күңелен күреп яшибез, – ди ул үзе. – Кем эшләми, шул ялгышмый. Тәҗрибә белән үсәсең, характерың ныгый. Шулай булырга тиеш инде. Тормыш бит ул. Карасы да, агы да була.

Уңган фермер Гөлфия Фәхразиева.

«КамАЗ» йөртүче Ирек Вәгыйзов.

22 декабрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Гөлгенә ШИҺАПОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Хезмәт ветераны» исеме бирерләрме?

«Россия Федерациясенең атказанган ветеринары» мактау грамотасын алган кешеләргә «Хезмәт ветераны» исеме бирелә дип ишеткән идем. Эштән киткән очракта биреләме икән ул? Документларны эштән киткәч җыеп тапшырырга буламы?

А.АРДАШИРОВА.
Нурлат районы Колбай-Мораса авылы

Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы матбугат хезмәте җитәкчесе Рафаил Гыйниятуллин:
– «Хезмәт ветераны» исеме СССР һәм Россия Федерациясенең орденнары, медальләре белән бүләкләнүчеләргә, Россия Президентының Мактау грамоталары һәм Рәхмәт хатын алучыларга, хезмәтендә аерым дәрәҗәләргә ирешүчеләр, ведомство билгеләре алучылар һәм бер өлкәдә кимендә 15 ел эшләүчеләргә (икътисад тармагында); пенсия билгеләү өчен исәпкә алынучы (ирләр өчен – 25 елдан ким булмаган һәм хатын-кызлар өчен 20 елдан ким булмаган) хезмәт (иминият) стажына, яки тиешле еллар выслугасы буенча пенсия билгеләү өчен кирәкле, календарь буенча исәпләнә торган тиешле еллар выслугасына ия затларга; Бөек Ватан сугышы чорында хезмәт эшчәнлеген балигъ булмаган яшьтә башлаганнарга һәм тиешле (ирләр өчен 40 елдан ким булмаган һәм хатын-кызлар өчен 35 елдан ким булмаган) хезмәт (иминият) стажына ия булганнарга бирелә.

Барлык кирәкле документларны җыеп, теркәлү урыны буенча, кеше социаль яклау бүлегенә мөрәҗәгать итә ала. Хезмәт ветераннарына торак-коммуналь хезмәтләргә түләгәндә 50 процент ташлама, телефонга түләгәндә субсидия, юлда йөрү өчен айлык социаль түләү, шулай ук бушка протез куйдыру, колак ишетмәүне дәвалау каралган.

Ачыклык кертәбез

1 декабрь санындагы «Халык авазы»нда басылган «Автобус нигә туктамый?» соравына Казан мэриясенең матбугат хезмәте өстәмә мәгълүмат юллады:

– Спутник навигациясенең борт комплектлары (ГЛОНАСС/GPS) мәгълүматы буенча, 91 маршрутның автобус йөртүчеләре тарафыннан кагыйдә бозу очраклары ачыкланмады. Алар расписание буенча йөриләр һәм барлык тукталышларда да туктыйлар. Расписание буенча, «Молодежная» тукталышына беренче автобус иртәнге 7 сәгать 15 минутта килә.

Ринат Мөхәрләмовның искәрмәсенә килгәндә, сүз, мөгаен, «ирекле» («нулевой») рейс турында барадыр. Ул вакытта шофер, автопарктан чыгып, башлангыч тукталышка кадәр бара. Регламент нигезендә, ул бу очракта тукталышларда туктарга һәм пассажирларны утыртырга тиеш түгел.

Укучы сүзе

Газетаның 1 декабрь санында Сәрия Мифтахованың «Кесә калынга түгел...» язмасына «Авыл халкы куркак, басым астында бирә. Яшисе бар бит, кем шундый зур акча бирсен?» дигән кайтаваз килгән. Нурлат районының Нариман авылында халыкның зур суммада үзара салым акчасы җыюлары турындагы язма ул. Мин күрше авылда яшим. Нариманда торучы юк, акчаны да пропискадагы кешеләр генә җыйды. Алар җәен кайтып йөриләр. Бирсен дә беркем дә мәҗбүр итмәде. Алар – гомумән, актив халык. Бәйрәмнәрен дә матур итеп уздыралар. Авыл җирлеге башлыгы да оештыру эшләрен бик яхшы башкара. Кыскасы, бу кайтавазны язган кеше дөрес аңласын иде: бу очракта ирексезләп акча җыю дигән нәрсә юк.

Нурлат районының Колбай-Мораса авылыннан
Мөнир ФӘРДИЕВ, 82 яшь

«ИСӘНМЕ, ЯҢА... БӘЯ!» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ
Автобуслар иске, салонда – зәп-зәңгәр төтен, солярка исе. Автобус идәннәре кич белән юылырга тиеш – анысы да үтәлми. Кондукторлар билет бирми, үз кесәләренә акча җыя. Санап китсәң, кимчелекләр бик күп. Салонда салкын, җәен эссе. Юл хакы үзгәрү үзен тулысынча хупламый.

Марат ӘМИРХАНОВ

***

Бәяне арттыралар – хезмәт күрсәтү начарлана. «Салават Күпере»нә 62 маршрут йөри. Тагын бер автобус өстәмиләр. Халык бик күп йөри бит эшкә.

Венера ШӘМСЕТДИНОВА

***

Ичмаса, мәктәп балаларына совет чорындагы кебек ташламалы проездной булсын иде.

Сания ГАБДУЛЛИНА

«САГАЕП КАРЫЙСЫ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ
Рәхмәт, кирәкле киңәшләр. Шулай, организм үзе сорый ул. Теләсә нәрсә эшләргә ярамый.

Хәлимә НӘҖИПОВА

***

Көн саен 10 мең адым (якынча 7–8 чакрым) җәяү йөрсәң, аяктан егылырсың.

Әнфисә ЗӘКИЕВА

ЮРИСТ КИҢӘШЕ

Редакциябезгә килеп ирешкән сорауларга «ВТ» юристы Булат ЗАКИРОВ җавап бирә

Акчасын кайтарып буламы?

Узган Яңа елга матурлык салонына сертификат бүләк иткәннәр иде. Аның гамәлдә булу вакыты ярты ел гына булып чыккан, игътибар белән карамаганмын. Сертификатны кулланмаган очракта, алынган акчасын кире кайтарып буламы?

ЗИЛӘ. Казан

– Закон нигезендә акчаны кире кайтарып була. Еш кына сатучылар сатып алучылар өчен төрле чикләүләр барлыгы турында әйтә. Әйтик:
– бүләк кире кайтарылырга яки алыштырылырга тиеш түгел,
– сертификатның гамәлдә булу вакыты тәмамланганнан соң аны файдаланып булмый,
– сертификат өчен акчаны кире кайтару мөмкин түгел.
Әмма бүләк ителгән сертификатны вакыты чыккан очракта да кибеткә кире тапшырырга мөмкин. Сатучының акчаны кайтарудан баш тартырга хокукы юк, бу РФ Граждан Кодексының 1102 маддәсе белән нигезләнә. Әгәр сезгә тиешле акчаны кайтармыйлар икән, Роспотребнадзор һәм судка мөрәҗәгать итә аласыз.

Паспорт белән нәрсә эшли алалар?

Кайчак эш буенча паспортны фотога төшереп җибәрергә туры килә. Хәзер бит кайсы гына социаль челтәрне алсаң да, мошенниклар сагалап тора. Паспорттагы мәгълүмат начар кулларга эләксә, нәрсә булырга мөмкин?

РИНАТ В. Кукмара

– Бу сорауга озаклап җавап бирергә мөмкин. Паспорт мәгълүматларын файдаланып, кешене алдау ысуллары күп, һәм алар артып тора. Мошенникларның схемаларын санап бетереп булмый, әмма берничә төренә тукталыйк: микрокредит алу, сезнең исемгә фирма теркәү, рассрочка рәсмиләштерү, электрон кошелек ачу. Сезнең исемгә рәсмиләштерелгән микрокредит булу-булмавын Дәүләт хезмәтләре порталы аша кереп карарга мөмкин. Шәхси мәгълүматларыгызга игътибарлы булыгыз. Мондый хәлгә юлыксагыз, хокук саклау органнарына хәбәр итегез.

Һәр өлеш өчен түләнерме?

Мирас булып Саклык банкындагы счетлар күчте. Акчасы күп түгел, совет чорыннан калган зур булмаган суммалар. Банк һәр өлеш (вклад) өчен компенсация түли дип беләм. Безнең очракта компенсация һәр өлешкә аерым тиешме икән?

Г. ӘСКӘРОВА. Казан

РФ гражданнарына Саклык банкы өлешләре (1991 елның 20 июнендәге мәгълүматлар буенча) өчен компенсация түләү тәртибе Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 25.12.2009 чыккан № 1092 карары белән билгеләнә. Аның нигезендә, компенсация түләүләре түбәндәге затларга башкарыла:
– 1991 елга кадәр туган РФ гражданнарына;
– 1991 елга кадәр туган РФ гражданнары варисларына – РФ гражданнары өлешләре буенча;
– 2001–2023 елларда банкта өлеше булган РФ гражданы вафат булса, ритуаль хезмәтләр өчен түләгән якыннарына яки башка физик затларга.
Шулай итеп, әгәр барлык өлешләр дә югарыдагы таләпләргә туры килә икән, компенсациягә хакыгыз бар.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

18 декабрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.0, 20.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 16.00 «Халкым минем…» 12+
12.00, 22.40 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «Сөйләшергә вакыт» 16+
17.40 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Кто мы татары?» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Tatarstan today. Открытый миру» 16+
23.30 «ЖЁЛТЫЙ ГЛАЗ ТИГРА» 16+
00.25 «Каравай» 6+
00.50 «Путь» 16+
01.05 «Туган җир» 12+
01.30 «Татар халык җырлары» 0+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05, 18.20, 22.15 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
12.35, 3.30 «Идрис Газиев тәкъдим итә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00, 18.50, 22.40, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25, 00.40 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Туган авылым» 12+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ИЩЕЙКА» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «Имена нелегальной разведки» 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
01.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
02.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Свидетели Эйзенштейна» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-23» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
04.00 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Спортивный век» 12+
06.30 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
07.00, 09.30, 13.40, 16.45, 20.50, 03.55 Новости 0+
07.05, 19.50, 23.00 Все на Матч!
09.35 «Лица страны» 12+
09.55 «Лучшие из лучших» 12+
10.55 Профессиональный бокс. Х. Агрба – Д. Бекбауов 16+
12.10, 03.35 Специальный репортаж 12+
12.30 «Есть тема!»
13.45 Футбол. Жеребьёвка Лиги чемпионов и Лиги Европы
15.25 «Громко»
16.55 Плавание. «Кубок Владимира Сальникова»
19.20 Матч! Парад 6+
20.55 Футбол. Клубный чемпионат мира
23.55 «Суперсерия 72» 6+
01.35 Дзюдо. FONBET Кубок России 12+
04.00 Бадминтон. Мировой тур 0+

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ЛИХАЧ» 16+
22.10 «БИМ» 16+
00.50 «ШПИОН №1» 16+
02.35 «АДВОКАТ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30, 06.20 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.20 «Давай разведёмся!» 16+
08.20 «Тест на отцовство» 16+
10.30, 23.15 «Понять. Простить» 16+
11.35, 00.25 «Порча» 16+
12.45, 01.20 «Знахарка» 16+
13.20, 01.45 «Верну любимого» 16+
13.55, 02.10 «Голоса ушедших душ» 16+
14.30 «Новый год по-домашнему» 16+
14.45 «ДВОЕ НА КРАЮ» 16+
19.00 «НАЙДИ МЕНЯ, СЧАСТЬЕ» 16+
02.35 «СТАРУШКИ В БЕГАХ» 16+
06.00 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «СМЕРШ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «ЩИТ И МЕЧ» 12+
12.40, 03.15 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. СКРЫТЫЙ ВРАГ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «Русская Арктика. Северный путь» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Ищу своих» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «ПУТЬ В "САТУРН"» 12+
00.50 «КОНЕЦ "САТУРНА"» 12+
02.25 «Перевод на передовой» 16+

19 декабрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 20.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Если хочешь быть здоровым» 16+
11.30, 15.45 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего…» 16+
14.45 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.15 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Авангард» – «Ак барс» 6+
19.00, 00.40 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Семь дней +» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.00 «ЖЁЛТЫЙ ГЛАЗ ТИГРА» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Если хочешь быть здоровым» 16+
01.05 «Башваткыч» 12+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Кәмит Җавит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 18.20, 22.15 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00, 18.50, 22.40, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
21.25 «Ком сәгате» 16+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ИЩЕЙКА» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «Имена нелегальной разведки» 16+
01.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
01.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Баден-Баден» 16+
02.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Россия и Запад на качелях истории» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Триггеры» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-23» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
04.00 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Спортивный век» 12+
06.30 Матч! Парад 6+
07.00, 09.30, 13.55, 20.50, 03.55 Новости
07.05, 14.30, 19.50, 23.00 Все на Матч!
09.35, 12.10, 03.35 Специальный репортаж 12+
09.55 «Лучшие из лучших» 12+
10.55 Смешанные единоборства. UFC. К. Усман – К. Ковингтон 16+
12.30 «Есть тема!»
14.00 «География спорта» 12+
15.15 Футбол. Журнал Лиги чемпионов 6+
16.20 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Авангард» (Омск) – «Ак барс» (Казань)
18.45 Смешанные единоборства. UFC. Л. Эдвардс – К. Ковингтон 16+
20.55 Футбол. Клубный чемпионат мира
23.55 «Бросок в прыжке: история Кенни Сейлорса» 12+
01.35 Дзюдо. FONBET Кубок России 12+
04.00 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «Уралмаш» – УНИКС 6+

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ЛИХАЧ» 16+
22.10 «БИМ» 16+
00.50 «ШПИОН №1» 16+
02.35 «АДВОКАТ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.15 «Давай разведёмся!» 16+
08.15 «Тест на отцовство» 16+
10.25, 23.10 «Понять. Простить» 16+
11.35, 00.15 «Порча» 16+
12.40, 01.15 «Знахарка» 16+
13.15, 01.40 «Верну любимого» 16+
13.50, 02.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.25 «Твой Домашний доктор» 16+
14.40 «ПО ТУ СТОРОНУ СОЛНЦА» 16+
19.00 «ГОРЬКИЙ МЁД…» 16+
02.30 «СТАРУШКИ В БЕГАХ» 16+
05.55 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. СКРЫТЫЙ ВРАГ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00 «ЩИТ И МЕЧ» 12+
13.25, 03.30 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. ЛИСЬЯ НОРА» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «В.С. Абакумов: «Прошу о справедливости…» 16+
18.50 «Специальный репортаж» 16+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «Часовые памяти. Воронеж» 16+
00.15 «БОЙ ПОСЛЕ ПОБЕДЫ…» 12+
03.05 «Хроника Победы» 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «АК БАРС» (гавами акционер җәмгыяте) коммерциале акционер банкының Иминлек департаменты директоры урынбасары **Журов** Николай Григорьевич Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Ватан алдындагы казанышлар өчен» I дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Төзелеш өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Күперләр төзү идарәсе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Мостафаев** Бәһрам Талыб углына Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә **«Россия Федерациясенең атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе нәтиҗәле эшләүләре өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте идарәсе җитәкчесе урынбасары **Абдрахманов** Рамил Айдар улына, В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең төзелеш проектларын тормышка ашыру идарәсе инженеры **Белова** Елена Михайловнага Россия Федерациясе Президенты боерыгы нигезендә **Россия Федерациясе Президенты Рәхмәте** белдерелде.

***

Республика мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен **Абдуллин** Шәүкәт Шәһвәли улы, **Байкиев** Ромил Коттус улы, **Нуруллина** Рәмзия Минвазыйх кызы; җирле үзидарә органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Егоркино авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары **Булатова** Алина Николаевна; һөнәри эшчәнлектәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Татарстан Республикасы Спорт министрлыгының «Спорт әзерлеге үзәге» дәүләт автоном учреждениесе директорының спорт чаралары оештыру буенча урынбасары **Иванов** Эдуард Владимирович, «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе башлыгы **Карпова** Наталья Владимировна, Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары **Плеханова** Ольга Анатольевна; республикада юл төзелешен үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Алексеевскдорстрой» ачык акционер җәмгыятенең участок башлыгы **Кәбиров** Фәнис Рәис улы; кадрлар сәясәтен гамәлгә ашыруга зур өлеш кертүе һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгы **Латыева** Татьяна Юрьевна; эчке эшләр органнарында күпьеллык намуслы хезмәте, законлылыкны һәм хокук тәртибен ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы ветераны, отставкадагы эчке хезмәт полковнигы **Фәхретдинов** Илшат Тәлгать улы; финанс-икътисад эшчәнлегендәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «Элай» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте аудиторы **Чухлин** Николай Михайлович **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисадый потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе 18 номерлы бүлеге башлыгы **Боталова** Нина Александровна, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының икътисадый анализ бүлеге әйдәүче киңәшчесе **Нуриев** Илзат Фәргать улы, хезмәт ветераны **Хәйрутдинов** Хәмит Кирам улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Казан шәһәренең «Стрела» физкультура-спорт берләшмәсе» спорт мәктәбе» муниципаль бюджет бестәмә белем бирү учреждениесе инструкторы-методисты **Павлова** Ольга Александровнага, «Татарстан Республикасының Баскетбол федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы башкарма комитеты әгъзасы **Сәетгалиев** Наил Кәрамәтулла улына **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Россия Федерациясе Үзәк банкы Ломбардлар буенча аналитика үзәгенең (Казан шәһәре) ломбардлар эшчәнлеген анализлау, җыелма һәм статистика эше секторы мөдире **Абдуллина** Венера Гомәр кызына, «Россия Саклык банкы» гавами акционер җәмгыятенең 8610 номерлы «Татарстан банкы» бүлекчәсе кредитлар бирү идарәсенең кредит инспекторы **Горькова** Любовь Александровнага, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының бюджетны үтәү бүлеге башлыгы урынбасары **Гурьянова** Эльмира Нэл кызына, «Казан шәһәренең азык-төлек һәм социаль тукланy департаменты» акционер җәмгыяте финанс директоры **Каюмова** Гөлнара Кадим кызына, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 10 номерлы районара инспекциясе күчмә тикшерүләр бүлеге башлыгы урынбасары **Гыйльметдинова** Ләйсән Рәфхәт кызына, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе банкротлык процедураларын тәэмин итү бүлеге башлыгы **Зазвонова** Ольга Борисовнага, Татарстан Республикасы Хисап палатасы аудиторы **Якупов** Александр Әбүзәр улына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының бюджет өлкәсе тармакларында бюджет сәясәте бүлеге әйдәүче консультанты **Гусева** Анна Александровнага, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе көч ведомстволарына хезмәт күрсәтү бүлеге башлыгы **Дяглюк** Венера Миназым кызына **«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ТУҢМАСА ДА ҖЫЛЫНМЫЙ

Бу атнада кыш кышлыгын итте – зәмһәрир салкыннары белән куркытты. Мондый көнне эчкә тиз генә җылы йөгерми. Әмма арабызда салкын көнне генә түгел, җылыда да җылына алмый тилмерүчеләр шактый. Сүзебез аяклары гел салкын кешеләр турында. Бу нәрсәгә бәйле? Салкын аяк чир билгесе була аламы?

Табиб-невролог, медицина фәннәре кандидаты Эльвира ЩЕРБАКОВА шул сорауларыбызга ачыклык кертте.

:: Аяклар гел салкын булуның сәбәбе нәрсәдә?

– Салкында кул-аякларның туңуы – табигый хәл. Ә менә аяклар даими рәвештә салкын булса, шикләнергә җирлек бар. Кешенең кан тамырлары, эндокрин, нерв системасы эшчәнлеге, матдәләр алмашы бозылганда, шикәр чире, калкансыман биз гормоннары аз бүленеп чыккан очракта да кешенең аяклары гел салкын булырга мөмкин. Гемоглобины түбән булган (анемия) кешедә дә еш кына әнә шундый билгеләр күзәтелә. Йөрәк тиешенчә эшләмәгәндә эчелгән дарулар да аякларның даими рәвештә салкын торуына китерергә мөмкин. Аякларның салкын булуы – бер хәл. Кайчак әле шуның белән беррәттән аякта тәзәлми торган яра, җәрәхәтләр дә пәйда булырга, кешенең атлап йөреше үзгәрергә, аяклар хәлсезләнергә, тән тиресе агарып чыгарга да мөмкин. Шуңа күрә аяклар даими рәвештә салкын торса, кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

:: Аяклар җылынмаудан күбрәк кемнәр интегә?

– Кечкенә балалар, бигрәк тә бер яше дә тулмаган сабыйлар температура үзгәрешләренә аеруча сизгер була. Шуңа күрә алар бик тиз туңа, бик тиз эссели. Аякларның даими салкынлыгы хатын-кызлар арасында күбрәк очрый. Аларда җылылык алмашы акрынрак бара. Артык ябык, озын буйлы кешеләрнең дә аяклары гел салкын була.

vk.com

:: Ул ничек дәвалана?

– Салкын аякларны дәвалар алдыннан, иң элек аларның ни сәбәпле шундый булуын ачыкларга кирәк. Моның өчен иң элек табиб-терапевтка мөрәҗәгать итү дөрес булыр. Ул барлык кирәкле тикшеренү, анализларны билгеләячәк. Кирәк икән, ул кешене тар белгечкә дә җибәрәчәк. Шул рәвешле даими салкын аякларны ничек дәвалау аны китереп чыгарган чирне дәвалаудан башлана.

:: Моны алдан кисәтеп буламы?

– Бу очракта да без даими әйтеп килгән киңәшләрне кабатларга мәҗбүр. Салкын аяклар чире килеп чыкмасын өчен, даими рәвештә диспансеризация узарга, йөрәк-кан тамырлары, калкансыман биз, нерв системасы авыруларыннан интеккән кешеләргә тиешле даруларны вакытында эчеп торырга, дөрес тукланырга кирәк. Даими рәвештә спорт белән шөгыльләнү, тәмәке тарту, исерткеч эчемлекләр куллану кебек начар гадәтләрдән дә арыну да мондый кимчелекләрне кисәтергә ярдәм итәчәк. Һава торышына карап киенү, өшү-туңулардан саклану да мөһим.

Аяклар салкынлыгын булдырмас өчен, тагын берничә киңәш

✓ Ешрак яланаяк йөрегез. Җәен – чыклы үләндә, вак таш өстендә, өйдә махсус массаж келәмендә йөрергә кирәк. Гомумән, азрак утырып, күбрәк хәрәкәтләнергә тырышыгыз.

✓ Контраст душ керү, аякларга контраст ванна ясау да файдалы. Бу кан тамырларын ныгытырга, ул исә, үз чиратында, аякларның даими рәвештә салкын торуын кисәтергә ярдәм итә.

✓ Һәр иртә саен аякларга массаж ясагыз. Моның өчен башта ике кул белән табан астын, аннары бер-бер артлы аяк бармакларын массажлагыз. Йоклар алдыннан аякларны ылыс суына яки диңгез тозы эретелгән суга тыгып утыру да файдалы булачак.

✓ Аякны аякка куеп утырырга яратучыларга да бу гадәтеннән арынырга киңәш ителә. Ник дигәндә, шул рәвешле 10–15 минут утырсаң, аяклардагы кан әйләнеше начарланачак.

✓ Кышкы салкында кысып торган, уңайсыз аяк киеме кияргә дә ярамый. Аның эченнән коры, җылы оекбаш кияргә кирәк.

✓ Иммунитетыгызны ныгытыгыз. Ашаганда С витаминына бай ризыкларга (гөлҗимеш, карлыган, цитруслар һ.б.) өстенлек бирегез. Алар кан тамырларын ныгытачак. Имбир белән ачы кызыл борыч исә алар буйлап канны куачак.

✓ Көненә кимендә 2 литр чиста су эчәргә дә онытмагыз. Организмга су җитмәгәндә, кан куера, кан тамырлары кысыла.

Саклап куй!

Борынга томау төшсә...

1 10 грамм кара әремгә бер стакан кайнар су агызып, 1 сәгать тонәткәч, шуны ашарга ярты сәгать кала көненә 3 тапкыр берәр аш кашыгы күләмендә эчәргә кирәк.

2 Урман чикләвеген кыздырып, борыч белән ашасагыз, томау бетәр. Зиһен ачылып китәр.

3 Күкертне яндырып, бүлмәгә төтен тарату да томаудан котылырга ярдәм итә.

4 Суган орлыгын кыздырып, киндер чүпрәккә төрегез дә борын эченә куегыз.

5 Яңа гына сыгылган меңъяфрак үләне согының 2–3 тамчысын көненә 5–6 тапкыр борыныгызга тамызыгыз.

6 Борын эчен, йоткылыкны көненә 3–4 мәртәбә тозлы су белән яисә үсемлек төнәтмәсе (мәсәлән, ромашка, пәйгамбәр тырнагы, эвкалипт һ.б.) белән чайкап торыгыз.

7 Чиле-пешле йомырканы җылы көе суырып эчү тамак төбе кытыкланып торганда (катар), йөткергәндә, эсседә тавыш беткәндә, сулыш җитмәгәндә һәм ютәл белән кан чыкканда файдалы.

Киңәш-табыш

Хәлсезлектән алоэ коткара

Хәл булмаганда ярты стакан алоэ согына 500 г төелгән әстерхан чикләвеге, 300 г бал һәм 3–4 лимон согы кушып болгатырга да шуны көнгә 3 тапкыр, ашар алдыннан 1әр чәй кашыгы эчәргә кирәк. Туберкулез вакытында 100әр г атланмай, бал, какао порошогына 150 г алоэ согы кушып болгатып, шуны көненә 3 тапкыр 1әр стакан кайнар сөткә 1әр аш кашыгы салып эчәргә кирәк. Томау төшкәндә, борын тишегенә яңа сыгылган алоэ согы тамызсаң да нәтиҗәсе озак көттермәс. Тамак авыртканда, алоэ согын шулкадәр үк суга кушып, тамакны чайкыйлар, аннары 1 чәй кашыгы сокны җылы сөткә кушып эчәләр. Теш сызлаганда, аның янына алоэ яфрагын куярга кирәк.

Чөгендер таш эретә

Үт куыгында таш булганда, чөгендер төнәтмәсе ясарга киңәш итәләр. Берничә чөгендерне юып әрчергә, вак итеп турап, суда пешерергә кирәк. Аның суы ширбәт кебек куерырга тиеш. Соңрак шуны сөзеп, караңгы төстәге шешәгә салып каплап куегыз да суыткычта саклагыз. Төнәтмәне көнгә 3 тапкыр ашар алдыннан стаканның ¼ өлеше күләмендә эчегез. Аны әзерләгән көнне үк эчсәң дә була. Шулай дәваланганда, үт куыгындагы ташлар әкренләп эреячәк. 21 көн дәваланыгыз, аннары 1 атна ялдан соң ширбәтне кабат кабул итегез. Шулай тоташ 3 тапкыр дәваланырга рөхсәт ителә.

Файдалы

КИШЕР САКЛЫЙ

Кореяча кишер ирләрдә мәни бизе яман шешен кисәтергә ярдәм итә. «Туклану һәм биотехнологияләр» үзәге галимнәре шулай дип ышандыра.Мондый кишердә барлык файдалы матдәләр саклана, составында үсемлек мае булгач, андагы витаминнар яхшырак үзләштерелә, ди белгечләр. Кишер составындагы каротиноидлар организмны зарарлы матдәләрдән, төрле чирләрдән, шул исәптән яман шештән дә саклый.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

СЫРНЫ ҮЗЕБЕЗ ЯСЫЙБЫЗ

Нурлат районының Бикүле авылында яшәүче Кәүсәрия Җамалетдинова җиде төрле сыр ясап сата. Бер тәмен белгәннәр инде кибетнекен ашамый.

Кәүсәрия Җамалетдинова сыр ясау серләре белән бүлешә

Һөнәре буенча хисапчы ул. Хәзергә вакытта җирле үзидарәдә җыештыручы булып эшли, буш вакытында исә сыр ясау белән шөгыльләнә.

– Интернеттан күреп тотындым бу эшкә. Мин әйтәм, кеше сөт сатып алып та ясый бит, ә безнеке – үзебездә. Тәвәккәлләп, «Российский» дигәнен әзерләп карадым. Шәп килеп чыкты. Менә шуннан китте инде. Аннан башка төрле рецептлар буенча «Косички», «Моцарелла», «Адыгей», «Качотта» һәм башкаларын ясап карадым. Иң авыры – «Российский». Җитешсен өчен 45 көн торгарга кирәк. Иренмәсәң, табышы бар, – ди Кәүсәрия.

Хуҗалыкта сигез сыер тоталар икән. Ун литр сөтне сырга дип калдыра да калганын хөкүмәткә тапшыра. Продукциясен башта интернетка куйгалаган. Хәзер инде каядыр барып, ия эзләп йөрергә кирәкми. Бер тәмен белгәннәр өенә килеп ала. Шәһәрдән, авыллардан да сораучылар бар. Бәясе – 600–900 сум тирәсе.

Төрле күргәзмәләрдә дә катнаша икән Кәүсәрия. Һәр сырның – үз тәмләткече. Әйтик, «Адыгей»га – укроп, «Качотта»га пажитник, кабак орлыгы, әстерхан чикләвеге куша икән. «Белпер кнолле» сырын шарчык кебек ясап, паприка, кара борычта әвәли. «Халуми» сырын кисәкләргә бүлеп кыздыра.

«Российский» сыр рецепты

Сөтне 75 градуска кадәр җылытып, 32 градуска кадәр суытасы. Гадәттә, 10 литр сөттән 800 грамм сыр чыга. Шушы күләмдәге сөткә 0,6 грамм оеткы (закваска), ярты бал кашыгы сыр ясый торган фермент саласы. Куе массага әйләнгәч, кисеп бутарга кирәк. Суның әчелеген бетерер өчен, кайнаган су өстим. Болгатып, формаларга салып, өч сәгать тыгызлыйсы һәм бүлмә температурасында 2 сәгать тотасы. Аннан тозлау процессы башлана. Тозлык өчен: 1 литр кайнаган су, 400 грамм тоз, 1 аш кашыгы аш серкәсе, ярты чәй кашыгы кальций хлориды кирәк. Һәр 500 грамм сырны 3 сәгать тозлы суда тотасы. Ул 45 көннән соң гына әзер була.

Сәрия МИФТАХОВА

Укучы киңәше

ЧҮПРӘ БУЛЫША

Коры чүпрәнең файдасы юк, дисәләр дә, яраннар өчен файдасын күрәм. 3 л суга бер кап коры чүпрә, бераз шикәр салып, җылымса су өстим дә 5 сәгать каплап тотканнан соң яраннарга сибәм. Гөлләрем гел шау чәчәктә утыра.

Җәүһәрия ӘХМӘТШИНА

20 ел үстерәм

Кибеттә сатылган цикламеннан мантып китә алмый. Ә менә үзең орлыктан үстергәннәре нык һәм көчле була. Төрле орлыклар сатыла торган кибеттә була аның орлыгы. Шуны алып үзегез сипсәгез, сабыр һәм түзем булганда, ул сезне бик озак чәчәкләре белән куандырыр. Орлыктан 20 ел үстерәм инде. Елның кайсы вакытында утыртсаң да була.

Гөлназ ГАЯНОВА

Исеңдә тот!

Йокы артык түгел

Салкыннар башлангач, күп йоклый башладым, дип зарланучылар бар. Әгәр йокы 10 сәгатьтән артмаса, монда борчылырга урын юк, ди белгечләр. Салкыннар – организм өчен стресс, ә аннан саклануның ул үзе юлын таба.

Ә йокы:

- авыруларга каршы торучанлыкны арттыра;
- аппетит һәм гәүдә авырлыгын көйли;
- кышкы депрессиядән саклый.

Тик йокы көн-төн урын өстендә аунап ятуга кайтып калырга тиеш түгел. Бары «сыйфатлы» йокы гына файдага була. Шуңа күрә түбәндәге киңәшләрне исегездә тотыгыз.

- Көн саен бер үк вакытта йокларга ятып, бер үк вакытта торырга тырышыгыз.
- Йокы бүлмәсендәге температураны башка бүлмәләрдәгедән түбәнрәк (18–20°С) тотыгыз.
- Даими рәвештә һавада йөрегез һәм спорт белән шөгыльләнегез.
- Йокы бүлмәсендәге дымлылык 40–60% чамасы булса яхшы.
- Йокы бүлмәсенә телевизор куймагыз, телефоныгызны караваттан читкәрәк алып куегыз.

Тәмле булсын!

ҮПКӘ-БАВЫРЛЫ ТУТЫРМА

Юныс Әхмәтҗанов рецепты

Кирәк: *1 кг үпкә-бавыр, йөрәк, 100 г дөге яисә 120 г карабодай ярмасы, 1 йомырка, 100 г суган, 300–400 г сөт яки шулпа, тәменчә тоз, борыч.*

Терлекнең үпкә-бавырын, йөрәген вак кына турап, суган кушып, иттарткычтан чыгарырга. Тоз, борыч сибеп, йомырка сытып, яхшылап болгатырга. Аннары сөт яисә салкын шулпа, дөге яки карабодай ярмасы өстәп болгатып, эшкәртелгән эчәкнең өчтән ике өлешенә генә катнашманы тутыралар да ачык башын бәйләп куялар. Бу катнашма сыек булырга тиеш. Аны бавыр белән ярмадан гына әзерләргә дә мөмкин.

Катнашманы эчәк тулганчы салырга ярамый, чөнки пешкән ярма бүртә һәм тутырма ярылып китәргә мөмкин. Әзер тутырманы уклауга бәйлиләр дә кайнап торган тозлы сулы кәстрүлгә батыралар һәм 30–40 минут пешерәләр. Табынга кайнар килеш чыгаралар. Пешкән тутырманы турап та, бөтен килеш тә майлы табада ут өстендә яисә духовкада кыздырып алырга була.

Белеп тор!

Аш кырку булса

Әгәр ашка тоз артыграк салынган булса, аны түбәндәге ысуллар белән «көйләп» карагыз.

1 Ашка туралган суган яки сельдерей өстәп, 30 минут кайнатсаң, тоз тәме көйләнә.

2 Аш серкәсен чама белән генә салганда артык тоз тәме кимеячәк, тәме дә үзгәрәк булачак.

3 Бәрәңге яки дөге өстәү дә кырку ашны ашарлык итәчәк.

Ә башка вакытта тозны аш пешеп чыгар алдыннан салырга тырышыгыз.

ПИЛМӘН КАМЫРЫ

Пилмән камырын ничек кенә ясап карамадым! Арада иң ошаганы, сыналганы шушысы булды.

Бер буш стаканга бер йомырка, бер аш кашыгы сыек май, бер чәй кашыгы тоз һәм стакан тулганчы җылы су салам. Шушы бер стакан сыеклыкка өч стакан он өстәп, озак итеп камыр басам. Ярты сәгать ял иттерәм һәм менә дигән камыр әзер!

Гөлфия РӘХМӘТУЛЛИНА

КАПКАГА ЮЛ АЧА

Бер рәхмәт мең бәладән коткара, ди халык. Рәхмәтне ишетү рәхәт, кайчак әйтү генә кыен. Кешеләр арасында бер-береңә рәхмәт әйтү – гадәти күренеш анысы. Әмма еш кына рәхмәтнең иң зурысын кемгә әйтергә тиешлегебезне онытып җибәрәбез. Аллаһы Тәгаләгә шөкер итү кайчак күләгәдә кала кебек. Шул ук вакытта булганына шөкер итеп, рәхмәтле булып яшәүчеләр дә байтак. Рәхмәтнең көче нидә? Аның әҗер-савабы зурмы?



vk.com

«Рөстәм» мәчете имам-хатыйбы Исмәгыйль хәзрәт БИККИНИН белән шул хакта сөйләштек.

:: Рәхмәтнең көче нидә?

– Рәхмәтле булу – ислам динебездә мөһим гамәл. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә беренче аятен: «Шушы галәмнәрнең хуҗасы Раббысы Аллаһка мактауларыбыз булсын», – диган сүз белән башлап җибәрә. Шушы «әлхәмдүлиллаһ» диган сүз мактау ягыннан да, Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтне белдерү өчен дә әйтелә. Рәхмәт белдерү иң җиңел гыйбадәтләрнең берсе булып тора. Нинди генә изге эш булмасын – сәдакамы, намаз, хаҗмы, уразамы – шуның белән без Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтләребезне белдерәбез. Сөенечле хәбәр ишетсәк, «әлхәмдүлиллаһ» дип әйтеп куя алабыз. Бу күп көч таләп итми. Шөкер сәҗдәсе дә кыла алабыз. Кеше җәннәткә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән генә ирешә ала. Бу дөньяда кешеләргә рәхмәтле булу мал-мөлкәтебезне дә киметми. Киресенчә, бу кешегә ярдәм арта гына барачак. Игелекне ихлас күңелдән, моның өчен берни өмет итмичә эшләргә кирәк. Кеше безгә рәхмәт белдермәсә дә, күңелебез төшмәсен, чөнки без аны Аллаһы Тәгаләгә рәхмәт йөзеннән эшлибез.

:: Без кешегә рәхмәтле була беләбез, ләкин еш кына Ходай Тәгаләгә рәхмәт әйтергә онытабыз. Раббыбызга рәхмәт әйтмәү гөнаһ саналамы?

– Без кешеләргә рәхмәт сүзләре җиткереп торабыз. Чөнки алар безнең тормышыбызны алып барырга ярдәм итәләр. Шул ук вакытта без кешеләргә рәхмәтле булганда күңелебез Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтле булудан да ерак булырга тиеш түгел. Без аның биргән нигъмәтләренә шөкер итәргә тиеш. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Әгәр Аллаһы Тәгалә кемгә дә булса иман хисе бирсә, шуннан ары да ул тормышына шикаять белдерсә, Аллаһы Тәгалә аның маңгаена «әлфахр» сүзен язып куяр», – диелә. Ягъни ул күңел фәкыйрьлеге, мал фәкыйрьлегенә дучар булачак, канәгатьсезлек хисе аның күңелендә мәңге яшәячәк.

:: Тормышы җайлансын, проблемасы хәл ителсен өчен, рәхмәт көндәлеге алып баручылар да очрый. Моның өчен аны кулдан тутырырга, көненә 100 рәхмәт сүзе язарга кирәк, диган ышану яши. Бу уңайдан да фикерегезне белдерсәгез иде.

– Әгәр кеше үзенең көндәлегенә тормышында булган нигъмәтләр өчен рәхмәтләрен дә теркәп булса, артык булмас. Ләкин шушы рәхмәтләрне теркәү безнең тормышыбызда нигъмәтне үстерәме, юкмы икән? Монысына дәлил юк. Ләкин шунысы хак: ул безгә күңелебезне ачык тотарга ярдәм итә. Шулай да Аллаһы Тәгалә каршында безнең рәхмәтләребез «әлхәмдүлиллаһ», «сөбханалла» дию, зикер әйтү аша беленә. Пәйгамбәребез бер хәдисендә: «Кешенең әгъзалары бар. Аллаһ каршында рәхмәтебезне белдерү өчен, шушы әгъзалар исеменнән безгә сәдака бирергә яки изге эшләр эшләргә кирәк», – диелә. Әгәр тормышыбызда булган яхшы вакыйгаларны көндәлегебезгә теркәп калдырсак, аннары берникадәр вакыттан аларны укыгач, Аллаһы Тәгаләгә булган шөкер хисләребез үссә, бу очракта аның файдасы бар. Шул ук вакытта бу масаю булмаска тиеш. Мондый көндәлекләр яңа максатлар булдырырга, яхшы эшләргә илһамландырырга тиеш.

:: Адәм баласы нәрсәләр өчен рәхмәтле булырга тиеш?

– Адәм баласы бу дөньяда яңа табыш, уңыш, булган сәламәтлек, исән-сау ата-анасы, нәселе, булган дәүләте – күңеленә хуш килгән бар нәрсә өчен рәхмәтле булырга тиеш. Әгәр кеше рәхмәтле, канәгать була белми икән, аңа үз өстендә эшләргә кирәк. Корьәнебездәге аятьләр дә бу дөньяда рәхмәтле булуның нинди мөһим мәсьәлә икәнен күрсәтә. Үз вакытында пәйгамбәребез төннәрен намаз укыган. Озак басып торганлыктан аның аяклары шешкән хәтта. Шулвакыт аның хатыны Гайшә анабыз: «Ярасулуллаh, синә бит инде җәннәт вәгъдә ителде, хаталарың гафу ителде, син – Аллаһның пәйгамбәре. Ни сәбәптән син шулкадәр үзеңне җәфалыйсың, намазларда төннәрен басып торасың?» – дип сораган. Шулчак пәйгамбәребез: «Минем Аллаh каршында шөкерле бәндәләрдән буласым килә», – дип җавап биргән. Шуңа күрә адәм дөньясы иң беренче чиратта Аллаһы Тәгаләгә рәхмәтле булырга тиеш. Ул кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәү мөһим. Кешеләр каршында рәхмәтле булу, аларның хакларын үтәү, аларның хакларын кимсетмәү исә кешелек дөньясына рәхмәтле булуны күрсәтә.

:: Рәхмәт капкасы нәрсә ул? Кеше өчен ул кайсы очракларда ябыла?

– Авылда элек 300 хуҗалык булса, хәзер 250ләп йорт калгандыр. Яшьләр аз, авыл картлар кулына калып бара. Колхоз таралды, эш урыны булмагач, яшьләр читкә китә. Шуңа күрә мәктәптә укучылар саны да кимеде. Шөкер, балалар туа әле, бакчага йөриләр, – дип авылдагы вазгыятьне аңлатты ул.

Улы да әтисе кебек фермер булырга хыяллана икән. Гаязның сыйныфта үзе генә укуында берничә начарлык та күрми ул.

– Элек утыз бала укыганда, аена бер мәртәбә генә сорыйлар иде. Хәзер улыма көн саен җавап бирергә кирәк. Бүген алган «4ле» элеккеге «5ле»гә тора инде ул. Башта сыйныфта өчәү иде алар. Берсе күченеп китте, берсен башка мәктәпкә бирделәр дип беләм. Улымның үзе генә укуын, киресенчә, шәп дип уйлыйм. Спортзалга йөргәндә дә тренер белән үзең генә шөгыльләнү күпкә нәтиҗәлерәк бит, – ди Ирек Хамадишин.

Нурлат. Илюткино

Нурлат районының Илюткино чуаш авылында быел сыйныфында түгел, мәктәбендә үк бер бала калган. Ул да булса – 1 нче сыйныф укучысы Артем Антонов. 2010 елда тугызъеллык мәктәп ябылган булган. Тагын бер елдан аны башлангыч итеп ачканнар. Узган ел өч сыйныфка барлыгы 7 укучы белем алган әле. Быел 4 нче сыйныфны дүрт бала тәмамлаган. Ә калганнар укуын күршедәге Якушкино мәктәбендә дәвам итә.

– Авылда 98 йорт бар. Озын урамлы авыл бу. Балаларга авыл мәктәбенә баруга караганда, тукталышка чыгу якынрак. Шуңа күрә әти-әниләр балаларын күрше мәктәпкә автобус белән йөреп укытуны кулайрак күрә. Артем исә үзебездә укырга булды. Дәрес бетүгә

Мәктәпне саклаучы бердәнбер укучы – Артем Антонов.

өенә кайтып китә. Җәяү йөрүнең берничә кыенлыгын да күрми, – ди укытучы Клара Федорова.

Аның әйтүенчә, Артем бер дә зарланмый. Әйбәт укый. Мәктәпкә укырга, язарга өйрәнеп кергән. Тик чуаш телен белми, аны укытучы өйрәтә. Кайбер вакытта гына: «Иптәш булмагач, күңелсез миңа», – дип ямансулап куя икән. Клара Федорова белән ничек тә булса кызык табарга тырышалар. Тәнәфестә бергә шашка уйныйлар. Мәктәп бакча белән бер түбә астында урнашкан. Анда ике сабый йөри. Кайчак, Артемга күңелсез булмасын өчен, хәл белергә керәләр.

Мамадыш. Дусмәт

Мамадыш районының Дусмәт мәктәбендә 34 бала белем ала. Иң күп дигән сыйныфта 8 укучы санала. Ә менә 5 нче сыйныфта Әнәс Һадиуллин үзе генә укый. Үзе – Иске Комазан авылыннан. Сыйныф җитәкчесе – инглиз теле укытучысы Айсинә Шәрифуллина. Мамадыштан көн саен 20 чакрым ара үтеп килә икән.

– Беренче генә уку елым әле. КФУның Алабуга институтын тәмамлап, быел укытырга кайттым. Шәһәр мине кызыктырмады. Яшь укытучы буларак, авыл мәктәбендә тәҗрибә туплау күпкә отышлы дип уйлыйм. Сыйныфта балалар күп түгел. Мәктәп матур, төзекләнделгән. Балалар әйбәт, – ди 23 яшьлек укытучы.

Әнәсне ул бик кызыксынучан, бар нәрсәне дә беләсе килә дип мактады. Спортны ярата икән.

– «Тормыш дәресләре», «Мөһим сөйләшү» кебек дәресләр дә керә. Әнәс видео карап, төрле сораулар бирә. Минусы – иптәшләре булмагач, ярышып уку мөмкинлеге юк. Игътибар күп, барысына да тиз төшенә. Күбрәк баланы укыту кызыграк миңа. Ни өчен дигәндә, төрле төркемнәргә бүленеп, командалап эшләргә мөмкин. Биремнәрнең уен формасындагысы да бар бит. Ул вакытта Әнәс: «Минем иптәш юк бит», – дип әйткәли. «Борчылма, парлап уйныйбыз», – дим. Укучыларда инглиз телен өйрәнү теләге бар. Начар билге куймыйм, – ди Айсинә.

Әнәсне укытучысы бик тырыш укучы дип мактый.

Илдар Мөхәммәтҗанов

АКЧАЛЫ УЕН

БАЛА КҮҢЕЛЕН КҮРҮ КҮПМЕГӘ ТӨШӘ?

Аларга берни кызганыч түгел! Ул һәм кызларының туган көннәрен билгеләп узган әти-әниләрдән мондый сүзне ишетергә туры килә. Купшы бәйрәмнәр уздыру, бер чарадан икенчесенә йөртү – бала кубызына биюме, әллә башкалар алдында үзеңне күрсәтүме? Балалар уены зурларның баш бәласенә әйләнмәсен өчен нишләргә? Яңа ел бәйрәмнәре алдыннан әнә шул хакта фикер алышабыз.

Туган көн – гаилә бәйрәме

«Әкият» татар дәүләт курчак театрының баш режиссеры Илгиз Зәйниев белән шагыйрә Резеда Гобәева ике бала тәрбияләп үстерә. Бәйрәмнәр уздыруга исә гаиләнең үз фикере бар.

– Хәзер әти-әниләр балалар бәйрәмен уздыруга бик зур игътибар бирә. Миңа калса, хикмәт әти-әниләрдә генә түгел, ә балаларның бер-берләреннән күреп сораулары, – ди бу уңайдан Резеда Гобәева. – Бер баланың туган көнен зурлап уздырсалар, шуны ук икенчесе дә сорый. Ләкин бөтен әти-әнинең дә мөмкинлеге юк, чөнки андый бәйрәмнәр кыйммәткә төшә. Әйтик, бәйрәм уздыру 50 мең сумнан да ким булмаска мөмкин. Чөнки балаларда акча эшләү ул – бизнес. Аның өчен төрледән-төрле мәйданчыклар ачып кына торалар. Хәзерге балаларны юк-бар әйбер белән дә шаккатырып булмый. Туган көнгә бару да чыгымлы эш бит, бер белмәгән кешегә шалтыратып: «Минем баламның туган көненә килегез», – дип әйтү минем өчен бик читен. Шәхсән үзем чыгымнан бигрәк, кешегә авырлык китерүдән бик уңайсызланам. Кайвакыт үзебезгә дә айга берничә туган көнгә барырга туры килә. Һәркайсына бүләген алып барырга, илтергә, көтеп торырга, алып кайтырга кирәк.

Резеда фикеренчә, бала туу кебек шатлыклы вакыйга әти-әни һәм әби-бабай, якын туганнар өчен генә кадерле.

– Шуңа күрә без соңгы вакытта балаларның туган көннәрен гаилә бәйрәме итеп уздырырга тырышабыз. Дуслар мәктәптә, бергә йөргән түгәрәкләрдә дә котлый ала бит. 1 декабрьдә улыбыз Хәйдәрнең туган көне узды. Башта ул да үзенчә планлаштырган иде. Ләкин мин аңардан: «Синә андый туган көн нәрсәгә кирәк?» – дип сорадым. Ул: «Бүләкләр өчен кирәк», – диде. «Улым, нәрсә телисең, шуны алып бирәм, тик туган көнеңне гаилә белән үткәрик», – дидем. Безнең өчен гаилә белән кайдыр бергәләп барып ял итү дә – зур бәйрәм. Чөнки әтиләренең дә, минем дә күп вакытыбыз эштә уза. Мондый җыелы, рәхәт сөйләшеп утыручылардан балаларның да, үзебезнең дә күңелебез була, – ди Резеда.

Аның фикеренчә, туган көннәр, бәйрәмнәр балага сайлау мөмкинлеген бирү, теге яки бу әйбернең кыйммәтен арттыру үрнәге булырга тиеш.

– Балага мотивация бирергә кирәк. Әгәр бар теләгән әйбере алдында булса, аның кадере дә булмаячак. Кызыбызның 10 яшенә кадәр телефоны юк иде. Туган көне алдыннан сайлау мөмкинлеген бирдем: «Туган көн ясыйбызмы, әллә телефон алабызмы?» – дип сорадым. Монда эш акча санауда түгел, ә балага сайлау мөмкинлеге бирүдә, – ди ул.

Алып баручы Зәмирә Рәҗәпова фикеренчә, балалар бәйрәмен, туган көннәрне һәрвакыт билгеләп узарга кирәк, чөнки балачак истәлекләре кешене гомере буена озатып бара.

– Без балаларның һәркайсына, үзләренең теләкләрен искә алып, бәйрәм уздырырга тырышабыз. Аяз инде – үсмер егет. Аның өчен шау-шулы бәйрәмнәр кызык түгел, бүләк кенә сорый. Соңгы елларда үзе шөгыльләнә торган хоккей командасына күчтәнәчләр алып барып сыйлыйбыз. Ә Данил туган көнен ел буе көтә. Бер бәйрәм узуга икенчесе турында уйлый башлый, аны төрлечә планлаштыра. Бәяләргә килгәндә, төгәл генә хәтерләмим, ялгышмасам, узган елгысы 30 мең сумга төште. Камиләбез 2 гыйнварда туды. Шуңа күрә Яңа елдан соң ел да туганнар белән җыелышабыз. 2–3 көн безнең йортыбыз туганнар, бала-чагалар белән тулы була. Аниматор, бәйрәм тортлары, бүләкләр... Кыскасы, һәр бәйрәмне дә истәлекле итәр өчен бар көчебезне куябыз, – ди ул.

Шаккатыру авыр

Ләйсән Галиәкбәрова инде тугыз ел Сабада һәм авылларда балаларга бәйрәмнәр оештыра. Заказлардан бушап торганым юк, ди ул.

– Сабада еш уздырам, ә менә авылларга сирәк чакыралар. Казанга да барганым бар. Миңа калса, Сабада кешеләр тагын да таләпчәнрәк һәм аларга бәйрәм саен яңалык кирәк.

Мин эшли башлаган елларда балаларны кызыксындыру, көлдерү, шаккатыру җиңел иде. Хәзер балалар артык иркә, хәтта кечкенәләрне дә шаккатыру, игътибарларын җәлеп итеп тоту бик авыр. «Шулай булырга тиеш. Аниматор моның өчен акча ала», – дип уйлый алар.

Клоуннар заманы артта калды, балалар яңалык көтә, шуңа күрә аниматор, балалар бәйрәмнәрен оештыручыларга да алар белән бер дулкында булырга, аларның ни белән кызыксынганын белергә туры килә. Шулай да авыл җирендә балалар ихласрак, – ди ул.

Бәяләргә килгәндә, Ләйсән әйтүенчә, аның программасы 4,5 мең сумнан башлап 7 мең сумга кадәр җитә. Ә иң еш сорала торган программалар 5–6 мең сум тора.

– Шәһәрдә генә түгел, авылларда да бәйрәмнәр уздыру – чыгымлы эш. Кунакларны өйгә дәшкән очракта да кимендә 20 мең сум акча барыбер тотыла, чөнки авылда балаларны бик күп чакыралар, – ди ул.

Ялтыравыклы тормыш

Психология фәннәре кандидаты, балалар психологы Люция Ибәтуллина фикеренчә, хәзерге җәмгыять – кулланучылар һәм нарцисслар җәмгыяте. Монда матди кыйммәтләр рухи кыйммәтләрдән өстенрәк чыга.

– Әйе, без рухи кыйммәтләр турында сөйлибез, ләкин гамәлдә матди кыйммәтләр белән күрсәтәбез, – ди белгеч. – Фатирыбыз булса да, зуррагын телибез, телефоныбыз булса да, кәттәрәген, шәбрәген сорыйбыз. Һәм боларның барысын да кешегә күрсәтеп эшлибез. Бу, әлбәттә, балаларда чагылыш таба. Социаль челтәрләр дә үз эшен эшли. Хәзерге балалар – блогерларны карап, алардан үрнәк алырга тырышып үскән буын. Аларны матур, ялтыравыклы тормыш җәлеп итә. Нарциссләр җәмгыятендә кеше фикеренә ихтыяҗ зур. Һәр төрле бәйгеләр, грамоталар, лайклар кешедә «мине бөтен кеше бәяли» дигән фикер тудыра. Бу балаларда һәм яшүсмерләрдә аеруча нык чагыла, аларның тормышка карашын үзгәртә.

Психолог фикеренчә, туган көннәргә бүләкләрне сорап алу да мөнәсәбәтләрнең «сәламәт» булмавына ишарәли.

– Ул әйбер аңа кирәк тә булмаска мөмкин, ләкин «башкаларга охшарга тырышу», теге яки бу әйбернең хуҗасы булу теләге барыннан да көчлерәк булып чыга. Хәзер балалар тиз өлгерә. 9 яшьтә инде яшүсмер чор башлана. Мин әйткән күренешләр бу вакытта аеруча көчле чагыла, чөнки әгәр син башкалардан аерылып торасың икән, сине читкә тибәрәчәкләр. «Мин дусламша белмим, шуңа күрә тышкы атрибутлар белән җәлеп итәм», – дигән идея барлыкка килә. Яшүсмер вакытта дуслык, билгеле бер төркемдә булу бала өчен бик мөһим, – ди ул.

Люция Ибәтуллина, әти-әниләрнең башка балага бүләккә акча бирүләрен хуплау бөтенләй дөрес түгел, ди.

– Бәйрәмнең максаты акча җыю, бүләкне «каплау» булырга тиеш түгел. Син бит баланың дусларын кунак итәсең. Әгәр мөмкинлегең юк икән, аны үткәрмәү хәерлерәк. Бүләк сайлау исә икенче кешенең кадерле икәнен күрсәтә, – ди ул.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Сораштыру

Гөлнур ФӘТХЕТДИНОВА (Чистай районы Исләй авылы):
– Балаларга 8, 6 һәм 1,5 яшь. Ел да туган көннәрен уздырабыз. Күпчелек вакытта өйдә генә утырабыз, районга уен зонасына да алып барганыбыз бар. Бәйрәм чыгымы шуннан карап хәл ителә. Кайдыр барсак, барлык чыгымнар 8 мең сумга кадәр җитә. Бүләкне 1 мең сумнан да кимгә алганыбыз юк. Шарлар, тортларга да заказ бирәбез. Өйдә гаилә белән генә билгеләп узганда 2 мең сумга да сыешабыз.

Гөлфинә КАЮМОВА (Казан):
– Моны һәр гаилә үз матди хәленнән чыгып хәл итә инде. Шулай да баланың кәефен күрер өчен, бюджеттан ничек тә өлеш чыгарырга тырышасың. Без дә барысын да балалар белән уртага салып сөйләшеп хәл итәбез. Өйдә гаилә белән генә билгеләп узуга да каршы түгелләр. Акча янчыгы нинди генә хәлдә булса да, Яңа ел бәйрәмнәрендә дә, туган көннәрдә дә балаларны игътибарсыз калдырганыбыз юк.

Гөлнара ХУҖИНА (Алабуга районы Морт авылы):
– Балаларга 3, 7, 10, 12 һәм 17 яшь. Гаилә бюджетыннан күпме акча бүленгәнен санаганыбыз юк. Без бүләк бирер өчен бәйрәм көнен көтмибез. Һәр баланың нәрсә белән кызыксынганын күзәтәбез дә һәркайсына яраклы итеп күп итеп төрле уенчыклар, китаплар, пазллар алып кайтып куябыз һәм шарларны гел биреп торабыз. Балаларның туган көннәрен яшьтәшләрен җыеп уздырырга тырышабыз. Үзем тамада булып, төрле уеннар уйнатып, бүләкләр биреп, кызыклы итеп үткәрергә тырышабыз. Кайдыр бармагач, өйдә генә уздыру чыгымлы түгел.

ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛЫП, БҮЛӘК ОТУЧЫЛАР:

«РӘХМӘТ ӘЙТЕП КЕНӘ ТОРАБЫЗ»

«Ватаным Татарстан» газетасы үз укучылары арасында бүләкләрне еш уйната. 2024 елның беренче яртыеллыгына язылучыларны да саллы бүләкләр көтә. Иң күңеллесе: бездән күчтәнәч алган һәркем редакция белән элемтәне өзми, хәл-әхвәл белешеп торабыз. Яңа ел алдыннан аларга шалтыратып, кәефләрен сораштык. Бездән алган бүләкләре һаман да хезмәт итә, үзләре безгә рәхмәт укый икән.

Фаварис ГАЛИЕВ (Балтач районы Смәел авылы)
2022 ЕЛДА МИНИ-ТРАКТОР ОТТЫ.
– Тракторымны олы улыма бирдем. Авылда тора ул. Янына төрле җайланмалар алып җибәрде дә әллә ниләр эшли хәзер. Минем бүләк отканны белгәч, каян гына котламадылар. Гомерем буе «Ватаным Татарстан» алдырган кеше бит мин. Сезгә язып та тордым әле. Әмма мине котлаучылар арасында Арча районының Шурабаш авылында яшәүче мари карты Федордан килгән хат иң якыны булды. Хатынымның энисе белән бергә эшләгән икән ул. Шулкадәр матур итеп котлап язган иде. Быел да газетага язылдым. Бүләк тә отасым килә. Бәхет эшен кем белсен, әллә тагын җиңәрмен! Тормышыма килгәндә, 82 яшемне тутырдым. Хатыным авырып китте, аны тәрбиялим. Вакыт табып, китаплар да язам. Бастырырга ярдәм итеп торучылар бар. Менә авыл тарихын барлый идем әле. Эше күп калмады инде. Шигырьләрем дә бар. Балалар өчен язганын шагыйрь Ленар Шәех алып киткән иде. Бәлки басылып та чыккандыр, үзем күрмәдем әле. Шулай итеп, картаерга да онытып яшәп яту. Сәламәтлек кенә булып торсын инде.

Әнисә ХӘСӘНШИНА
(Зәй районы Дүртмунча авылы)
2022 ЕЛДА ТАНДЫР ОТТЫ.
– Рәхәтләндек без ул тандырга. Машинага сыймыйча куркытса да, бакчада үз урынын тапты. Җәй буе оныкларны сыйладым. Шалт итәбез дә шашлык пешереп алабыз. Бер ягып җибәреп, кыздырып аласың да, карыйсы да түгел. Ризык көйми дә, үз җылысында пешеп тора. Ул вакытта бүләк отып булмасмы дип квитанция җибәреп йөргәндә, авылдашларым, ышанасыңмы шуңа, дигән иде. Янәсе, дөрес уйнатмыйлар. Бүләкне алып кайткач ышандылар инде. Тандырны күршеләрем дә кереп карады. Мин бүләк өчен сезгә гел рәхмәт укыйм. Газетага быел да язылдым. Интернетта да карап барам. «ВТ»ны бездә яраталар. Ирем дә, балалар да укый. Бүләкле булу өстенә сезнең дуска әйләнүемә дә сөенәм. Һәрберегез якын. Иҗат уңышлары телибез. Язылучыларыгыз күп булсын.

Фирдәүсә МИНГАЛИЕВА
(Питрәч районы
Ленино-Кокушкино авылы)
2020 ЕЛДА
КЕР ЮУ МАШИНАСЫ ОТТЫ.
– Кер юу машинасы оттыгыз, килеп алыгыз, дип шалтыраткач, кан басымы күтәрелеп киткән иде. Баштарак ышанмадым да. Бүләк өчен көн дә рәхмәт укыйм. Шулкадәр яраттым мин аны. Балаларым да: «Әнигә нинди зур бүләк булды бит!» – дип сөенеште. «Бигрәк бәхет елмайды сиңа», – диләр. Балалар бакчасында эшләүче хезмәттәшләрем барысы да сезнең газетага языла. Бөтен кешегә мактап сөйлим. Әле менә үзем киләсе елга язылмаган. Бер-ике көн эчендә язылып чыгабыз инде. Аннары квитанциябезне җибәрербез. Кем белә, бәхет тагын елмаймасмы? «ВТ»ны бик ошатып укыйбыз. Бар язмалары да күңелгә якын. Рецептларны кулланабыз. Сез минем якын дусларыма әйләндегез.

Шамил ВӘЛИЕВ (Арча)
2021 ЕЛДА ВЕЛОСИПЕД ОТТЫ.
– Әнием, «ВТ»га язылып, квитанцияне бәйгегә җибәргәнен әйтмәгән дә иде. Җиңдегез, дип шалтыраткач, бик рәхәт булды. Инде тормышымда да, эшемдә дә үзгәрешләр бар. Йөргән кызыма тәкъдим ясадым. Апрельдә туй итәргә исәп. Эшемдә вазыйфамны күтәрделәр. Әнием генә авырып китеп куркыткан иде. Шөкер, әкренләп уңайлана инде. Аның янында абыем бар. Ул тәрбияли. Әле абыемның да хатыны үлеп китте. Хәзер баласын ул үстерә. Тормыш шулай инде, күңелле хәлләр белән борчуы да бергә бара. Алга таба бар да яхшы булсын иде, дип телим. Әниебез исән-сау булып, авырлыкларны бергә җиңеп, борчуларда терәк булсак иде. Мин сезгә бик рәхмәтлемен. Бүләк отканымны газетада язгач, Арчадагы дуслар котлады. Интернетта да минем өчен шатланучылар күп булды.

Кадрия ШӘЙДУЛЛИНА
(Чүпрәле районы Түбән Каракитә авылы)
2020 ЕЛДА ТЕЛЕВИЗОР ОТТЫ.
– Мин телевизор откач, күршеләр белән очрашып, рәхәтләнеп чәй эчтек. Авыл халкы шаккатты инде. Уйламаганда бүләк бирсәләр, рәхәт бит ул. Газетагызны бик яратам. Башта үзем укыйм, аннан кешеләргә укытам. Быел 85 яшьлек Сания апа Шакирова үзе язылып кайткан. «Син укыганны көткәнче, үземә килсен әле», – ди. Газетада төпле, кирәкле язмалар гына басылуын бар кешегә сөйлим. Әллә ничә кешене яздырттым инде. Барыбызның да квитанцияләрен җибәрдек. Хәзер бүләк уйнатканны көтәбез.



Саимә ХАРИСОВА
(Әлмәт районы Яңа Кәшер авылы)
2020 ЕЛДА СУЫТКЫЧ ОТТЫ.
– Мин ул чакта бүләк отканыма башта ышанмадым да. Газетада исем-фамилиямне күргәч, аптырап киттем. Аннан: «Саимә, сөен!» – дип, үземне селкетеп җибәрдем. Гомерем буе алдырган газетамнан бүләк от әле! Телсез дә калырсың. Моннан 18 ел элек йорты янып беткән кеше мин. Анда да яхшы кешеләр булышты. Сездән суыткыч алганда да шаккаттым. Суыткычым юк иде бит. Казанга барып, коллектив белән күрешеп кайтуымны әле дә онытмадым. Бик якын кешеләремә әйләндегез. Хәзер суыткычны ачкан-япкан саен сезне искә төшерәм. Гомерем буе рәхмәт укырмын. Быел әле язылырга өлгермәдем. Хат ташучыны көтеп торам әле. Ул керүгә, язылып, сезгә квитанциясен юллар идем.

Әнисә ГАТИЯТОВА (Саба районы Олы Кибәче авылы)
2022 ЕЛДА СУЫТКЫЧ ОТТЫ.
– Бүләкне алып кайткач, әллә ничә кешене газетага яздырттым. Суыткычны күреп тә кызыктылар инде. Газетагызны бик яратам. Киләсе ел өчен 12 төрле басмага язылып куйдым инде. 7 мең сум акча тоттым. Аның каравы кыш буена укып кына ятасың. Иремә спорт турында язма белән атналык программа җитә. Ул телевизор карый, мин көн-төн укуда инде. Малларыбыз күп. Сыер савам, атыбыз, үгезебез, бозауларыбыз бар. Аларны бергәләп карыйбыз. Мин газеталарны төнлә генә укый алам. Йокым калса кала, һәр хәрефен укып чыгам. Әле менә шатлыгыбыз бар. Ноябрь аенда улыбызны өйләндердек. 65 яшьтә дип тормыйм, заманнан да калышмаска тырышам. «ВТ»ның социаль челтәрләрендәге сәхифәләрен дә карап барам. Зур эш башкаруыгыз өчен мең рәхмәт сезгә!

Гөлгенә ШИҺАПОВА
Илдар МӨХӘММӘТҖАНОВ фотолары

ОЛЕГ ФАЗЫЛҖАНОВ:

«КҮПНЕ КҮРГӘН КЕШЕ СӘХНӘДӘ ҮЗЕН УЙНЫЙ»

Рольләре усал, үзе нечкә күңелле. Сәнгатьтә нинди генә юнәлешне сайласа да, уңар иде кебек. Тамашачы аны актер буларак та, җырчы буларак та кабул итте. Ул – Түбән Кама театрына да, Камал театрына да үз кеше. Сүзебез – Татарстанның халык артисты Олег ФАЗЫЛҖАНОВ турында. Без аның белән мәдәният, театр хәлләре, борчыган мәсьәләләр турында, үзе әйтмешли, «по душам» сөйләштек.

:: Олег абый, сәхнәдәге уенына актерның язмышы ни дәрәҗәдә тәэсир итә?

– Синең күргәннәрең, тормыш багажың сәхнәдә чагыла, билгеле. Күпне күргән кешегә уйнарга кирәкми, ул күп рольдә үзен күрә. Әйтик, Кариев театрында барган «Микулай» спектакле ул – минем тормышым.

> Вакыт бара, дөнья үзгәрә. Сәхнәдә уйнау алымнары да үзгәрде. Без укыган вакыттагы мәктәп белән хәзергесе арасында аерма бик зур. Миндә һаман элеккеге уйнау алымы җиңеп бара. Ләкин ялгышмыйм дип уйлыйм. Чөнки театрга йөрүчеләр безнең буынны белә. Миңа калса, элеккеге мәктәп, мода шикелле, бер кире кайтыр әле.

:: Мөмкинлек бирелсә, тормышыгызда нәрсәне дә булса үзгәртер идегезме?

– Мин шундый кеше инде, ничек кенә булса да, хәтердә гомеремнең якты мизгелләре генә саклана. Алда тагын ни көтәдер, үткәнемә мең рәхмәт дип яшим. Үкенмим. Бернәрсәне дә үзгәртмәс идем.

Без алтын чорда яшәдек. Гәрчә, әйбер юк, фәлән юк, төгән юк иде, дисәләр дә. Аның каравы тапкан әйберләрнең кадере зур иде. Яшьтән үк шук булдым. Аның сере бик гади: үземне якларга кирәк иде, мине үземнән башка беркем дә якламый – моны бик иртә аңладым. Әле дөньяны танып белә башлаган гына вакытта, алты яшемне тутырганда, әтисез калдым. Аннары инде урамда сугышканда да, кемдер «әтигә әйтәм» дип кайтып китә, ә мин алай дип әйтә алмадым. Әтидә дә үкенеч булгандыр. Ул нечкә күңелле, сәнгать җанлы иде. Нишлисең, хәмер дигән әйбер туры юлдан барганда салулата, тормышны җимерә. Яшерен-батырын түгел, миндә дә булгалады ул. Бу чир кемнедер күбрәк суырып ала, кемнәндер өстән-өстән генә китә. Менә шул тормыш арбаң салулаган вакытта, абынган чакларыңда яныңда сине аңлаган кешеләрнең булуы кирәк. Мин бу җәһәттән уңдым.

Түбән Кама театрында эшләгән чорда йолдызлык чире дә булып алды, аны да исән-сау кичердек. Инде яши генә башладым дигәндә, 23 яшендә абый гүр иясе булды. Тәмам аякка баскач, әни китеп барды. Мондый хәлләр дә җыела-җыела чыныктыра, үз-үзеңне саклау инстинктын көчәйтә икән.

Аннары тормыш бик кызык бит ул: инде булды дигәндә генә, сиңа арты белән борыла да куя. Миңа максатыма урау юллар аша ирешергә туры килде. Аның каравы ләззәтле, тәмле итеп.

:: Театрны ташлар чиккә җиткән булдымы?

– Юк, алай дип уйлаганым булмады. Хәер, театрга килү юлы да җиңел булмады. Училищеда укыган чакта ук Камал театрында спектакльләрдә уйнап йөрсәк тә, сезнең группадан ике генә кешене алабыз, диделәр. Шунда үҗәтлек кабынды. Әчке сиземләү дигән әйбер дә бар бит әле. Миндә ул көчле, күрәсең. Укыган вакытта ук Чаллы, Түбән Кама, Әлмәткә баручы автобусларны күрсәм дә, йөрәк жу итеп куя иде. Тикмәгә булмаган бит, язмыш шул якларга илтте. Дөрес, Әлмәт театрында озак эшләргә туры килмәде, армиягә киттем, аннары... Тинчурин театрында, Дамир Сираҗиев белән эшләргә ниятләп кенә куйган идем, әни, ялгызымны калдырасыңмыни, дигәч, авылда калдым. Рөстәм Галиев, Түбән Камада театр оештырабыз, дигәч, анда эшләдем. 14 елдан соң гына Камал театры сәхнәсенә аяк бастым. Без, перефериядән күтәрелгән артистлар, теләсә кайсы сәхнәдә дә эшли алабыз, дим мин. Ә менә хәзер инде башкаладан авыл-районнарга китеп эшли алучылар булса да, бик азлар гынадыр. Уңайлылык, рәхәтлек изрәтә бит ул, аннан чыгулары кыен. Гәрчә хәзер инде бөтен җирдә дә уңайлыклар тудырылган булса да.

Театрдан Түбән Камада эшләгән чакта арыган идем анысы. Өсте-өстенә спектакль, артистлар аз булгач, һәрберсенә дә роль була. Шунда Рөстәм Галиевкә: «Нормальный кеше шикелле, спектакль каратып утыртасыңмы мине, юкмы?» – дип әйткәнем булды. Менә хәзер инде җәелеп карыйм.

«Театрны ташлар идеңме?» дигәннән, кеше ышанмастай бер хәлне дә сөйлим әле. Хәния Фәрхи белән эшләгән чак иде ул. Аның бер иганәчесе, Хәния командасында эшләү шарты белән, ике бүлмәле фатир тәкъдим итте. Театрны ташлап, әлбәттә. Китә алмадым. Ә эстрада тормышымда барыбер параллель рәвештә барды.

:: Актер бәхете – режиссердан, диләр.

– Актерның язмышы – режиссер кулында. Сине күреп ала, уеныңны ярата икән, рәхәтләнеп иҗат итәргә генә кала. Мин ул яктан уңдым. Түбән Камада Рөстәм Галиев нәрсә теләсәм, шуны уйнатты. Ничек теләсәм, шулай эшләтте. Камал театрында да килгән шәпкә Фәрит Бикчәнтәев бөтен спектакльләргә диярлек алды. «Телсез күке»дәге Зарифымны мин әле бүген дә сагынам. Бик авыр эшләнсә дә, ә бәлки авыр эшләнгәнгә күрә дә, бик кадерле, бик якын ул миңа. Аннары бер-бер артлы рольләр китте. «Талак-талак» (Хәй Вахит), «Тимер борчак» (Равил Бохараев), «Мулла» (Туфан Миңнуллин) спектакльләрендәге рольләремне шундый яратып уйнадым һәм сагынып искә алам.

> Театр артисты буларак, уйнамадым, күрмәделәр дип зарлану гөнаһ булыр иде. Дөрес, Камал театрына килеп кергәндә, үземне артист буларак өлгереп җитешкән дип саный идем. Түбән Камада мин үзем «диктовать» итә идем, ә монда миңа шартлар куйдылар.

:: Кариев театрында куелган спектакльдәге «Микулай» роле иң үзенчәлеклесе булып тоела. Үзегез дә «кадерле роль» дисез бит.

– Микулай ул – минем икенче кадерле спектаклем. Беренчесе Түбән Кама театрындагы «Кызлар кызык иттеләр» спектакле иде. Туфан абыйның «Ак тәүбә, кара тәүбә» пьесасы буенча куелды ул. Шушы театр, шушы роль дип, авылдан төнге сәгать бердә чыгып киттем. Клубта эшләгән килеш. Ул – минем беренче сәхнә җимешем, балам. Хәер, бөтен рольләр кадерле. Ә «Микулай» үзенчәлекле. Минем анда Микулай образы аша керәшеннең «душа»сын ачасым килде. Ул рәхәтлек бирә торган роль дә түгел, киресенчә, кыйный, сыный. Премьерадан соң бармакларымны өздердем хәтта. Шуннан, әллә баш тартыйммы икән бу рольдән, дигән уйлар да килде. Чөнки анда кереп китәсең дә чыга алмый интегәсең. Әмма андый рольләр бөтен кешегә дә тәтеми һәм бик сирәк эләгә.

:: Фильм турында («Микулай») ни әйтерсез?

– Аның спектакле дә гыйбрәт, фаҗига иде. Бу җәһәттән Кариев театры режиссеры Ренат Әюповка рәхмәт, ул пьесаны бик нык редакцияләде. Мансур Гыйләҗев үпкәләмәсен, ул яңадан язган кебек булды. Нәтиҗәдә керәшеннең «душа»сын ачтык кебек. Спектакль караңгы килеп чыкмады. Әле менә бүген Баулы халык театры куйган «Шулай булды шул» (Туфан Миңнуллин) спектаклен карап кайттым. Менә шундый якты әсәрләр җитми икән җанга. Ә «Микулай» фильмы ул керәшеннәр турында түгел. Анда теләсә кайсы халыкны күрергә була. Мөгаен, финанс мәсьәләсен хәл итәр өчен әнә шундый милли эз (бизәк дип әйтеп булмый инде аны) кертергә кирәк булгандыр. Әйе, фильмда үзем дә уйнадым. Бөтенесе ах иткән Сухоруков белән уйнау ничек икән – шуны беләсем килде. Өметем акланмады. Монда керәшеннең «душа»сы ачылмады.

Блиц-сораштыру

– Сайларга туры килсә, кайсын сайлар идегез: театрнымы, җыр сәнгатенме?
– Күптәнге хыялым тормышка ашып ята әле. Рәхәтләнеп, бирелеп, җыр сәнгате белән яшәгән көннәрем. Миңа, театр актеры булгач, бусы нәрсәгә инде сиңа, дип әйткәләгәннәре булды. Кешенең нәрсәгәдер омтылышы булмаса, яшәүнең кызыгы бетә. Менә әле актер буларак дилбегәләрнең бушаган чагы. Чөнки без инде шундый яшькә җиттек, мин аны торгынлык чоры дип тә әйтмим, ну әзрәк син «ни туда, ни сюдарак». Аны бөтен актер кичерә. Инде бу яшьтә 2 – 3 елга бер әйбәт роль булса, бик яхшы. Бәс, шулай икән, нишләп әле җырламаска? Быел яздан бирле концертлар белән йөрим. Авылларда бик җылы кабул итәләр. Казанда да концерт куярга ният юк түгел. Шунысы гына бар: миңа гомер-гомергә оештыру эшләре авыр бирелде. Шуңа күрә дә хыялым тормышка ашмагандыр да.
– Камал театры ул – ...
– ...минем өчен кадерле урын.
– Иң зур теләк?
– Дөньялар тыныч булсын!

:: Фильмнарда катнашып, халыкка тагын да күбрәк танылдыгыз кебек. Әмма ни өчендер өлешегезгә тискәре образлар күбрәк тия. Сәбәбе нәрсәдә икән?
– Мин актерларның тормышлары турында китаплар укырга яратам. Документаль фильмнар да күп карадым. Әйтик, менә Александр Демьяненко Шурик образыннан шулкадәр арый, шул хакта сүз чыкса, хәтта җенләнә башлый торган булган. Миндә дә шундый нәрсә. Режиссер бер планда күреп ала да сине башка яклап ачмый.

:: Тискәре рольләр сезгә бик мач килеп тора бит.
– «Өч аяклы ат» фильмыннан соң Мамадышта бер авылда концерт алып барган идем. Сәхнәдән төшеп барганда, бер әби сыртка таяк белән китереп сукты. Сыртка суктырырлык булгач, нык әшәке итеп уйналган, күрәсең. Ышанганнар.

– Мәдәният өлкәсендә иң борчыганы нәрсә?
– Иң борчыганы – тәҗрибә ясаулар артып китте. Үзгәртеп корулар теңкәгә тия башлады. Ул һәр өлкәдә дә шулай. Мин тәҗрибәләргә каршы түгел, үсеш өчен анысы да кирәк. Әмма хәзер баланс бозылды, тәҗрибәләр өскә чыкты. Милли әсәрләр икенче планга калды. Яхшылыкка өндәгән әсәрләргә көн бетте. Экияткә дә ышанып та яшисе килә бит. Нәрсәгә алынсалар – шуны яңарталар. Мин моны бөтенләй аңламыйм. Бизәлеш тә, әсәр дә – барысы да шартлы. Элеккечә дип авыз ачсаң, нафталин, диләр. Нафталинны да иснисе килә кайчак. Ул Көнбатышка шаккаттылар инде. Шекспир әсәрләре шәп анысы, сүз дә юк. Ә син үз әсәреңне Шекспир дәрәҗәсенә күтәреп, башка илләр кызыгырлык итеп куеп кара! Татар җырларына Мәскәүдә аранжировка ясатып кайталар. Ул нинди татар җыры булсын? Тәмам югалтып, шаклар катып калырбыз микән инде? «Кара урман»нарыңны югалттыңмы – милләтеңне югалттың дигән сүз бит ул.

– Балаларыгыз актер булам дисә, ни диярсез?
– Кем булам дисәләр дә, аларның теләкләренә каршы килмәячәкмен. Мине әни соңгы сыерын сатып укытты, аңа бик рәхмәтлемен. Балаларым талантлы, киләчәктә кем булам дисәләр дә, ярдәм итәргә тырышырмын. Беләсеңме, мин бит әти игътибарын күргән, аның тәрбиясен алган кеше түгел. Теләгәнемә үзем ирешкәч, балаларым да теләгәннәрен үзләре эзләп табарга тиеш кебек. Бу җәһәттән башка әтиләрне күзәтәм һәм, кара әле, мин бит үз балаларыма боларны эшләмәдем, дип куям. Балаларга наз дигән әйбер кирәк. Ата назы да, ана назы да. Шуңа балаларга игътибарлы булырга тырышам. Алардан бик разый, бик рәхмәт. Әйдә, гаилә темасын калдырып торыйк, күз тияр.

– Киләсе елны Гаилә елы дип игълан иттеләр. Бу елдан нәрсәдер өмет итәсезме?
– Гадәттә, авырткан җирне тартып чыгарып, аны күтәрергә тырышалар инде. Гаилә институтының хәле мактанырлык түгел. Яшьләрнең торырга урыны булмаса, ипотека процентлары котырганнан-котырса, гаилә дип авыз ачучылар күпме генә булыр? Инде андый ел игълан итәләр икән, иң беренче торак мәсьәләсе хәл ителсен иде. Җәмгыять байлардан гына да, хәллеләрдән генә дә тормый. Аның канализация чокырын казучысы да, урам себерүчесе дә кирәк. Кибеткә кереп, теләгәнен аламы ул? Талантлы кешегә югары белем алу мөмкинлеге бармы – бүген бюджет урыннары калмады да диярлек бит. Шушы сораулар уңай хәл ителсә, менә булыр Гаилә елы.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Бу көннәрдә без зур кайгы кичерәбез. Якын дустыбыз, киңәшчебез Рим Шәфыйк улы Халитов 79 нчы яшендә арабыздан мәңгегә китте. Тәвәккәл, принципиаль, тугры, профессионал – Рим дустыбыз үзенә барлык уңай сыйфатларны туплаган иде.

Тумышы белән Оренбург өлкәсенең Матвеевск районы Югары Яңакотлымбәт авылыннан булган бу шәхес ил тарихында саллы эз калдырды. Хезмәт юлын гади тракторчыдан башлаган Рим зур дәрәҗәләргә ирешә. Казан инженер-төзелеш институтын тәмамлап, гомере буе һөнәренә тугры булды. Бу тармакта төрле баскычларны үтеп, ул 1984 елда ТАССР Министрлар Кабинеты каршындагы Капиталь төзелеш идарәсе җитәкчесе итеп билгеләнде. Аннан соң Татарстан Республикасының төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары, Баш инвестиция-төзелеш идарәсе җитәкчесе булып эшләгән чоры да горурланып искә алырлык. Аның тәҗрибәсе Татарстанда төзелешне базар мөнәсәбәтләренә күчү чорында да саклап калырга ярдәм итте. Рим Халитов катнашында әзерләнгән һәм ул җитәкләгән дәүләт инвестиция программалары, дәүләт төзелеш заказлары республиканың бик күп төзелеш оешмаларына эш бирде. Аның җитәкчелегендә башкалабыз Казанның меңьеллык юбилее, Универсиада, футбол буенча дөнья чемпионаты объектлары төзелде, берничә йөз мәктәп, хастаханә, мәдәният һәм сәламәтлек саклау оешмаларының биналары сафка бастырылды. Хөкүмәт йорты, Казан аэропортының яңа бинасы, РКБ диагностика үзәге һәм башка, республикабызның горурлыгы булган зур объектлар – Рим Халитов эшчәнлегенең нәтиҗәсе.

Соңрак ул «Татарстан төзүчеләре бердәмлеге» җитәкчесе булды. Аның тырышлыгы нәтиҗәсендә төзелеш өлкәсендәге бик күп мәсьәләләр хәл ителде.

Шактый кырыс, авыр тармакта зур җитәкче урыннарда эшләвенә карамастан, Рим дустыбыз һәрвакыт нечкә күңелле, хәлгә керә белүче, киң күңелле, тормышны яратучы кеше булып калды. Аның шигырьләр язуы үзе үк күп нәрсә турында сөйли. Рим Халитов сүзләренә язылган җырлар безгә бүген дә онытылмас истәлек булып яңгырыйлар.

Римнең гаиләсенең, якыннарының кайгысын уртаклашабыз. Безнең күңелләрдә Рим Халитов дуслыкка тугры, көчле рухлы, ярдәмчел, иҗади шәхес булып сакланачак.

Тыныч йокла, дустыбыз!

М.Г. ӘХМӘТОВ, А.Г. ХӘКИМОВ, М.Х. ЗАРИПОВ, Р.Ш. ЗЫЯТДИНОВ, Н.Д. ДЕНИСОВ, Ю.И. СОЛУЯНОВ, И.М. ЗАКИРОВ, М.В. РИЗВАНОВ, И.З. ГАРИФУЛЛИН, Р.З. БИКБОВ, Р.А. АБДУЛВАҺАПОВ, Р.А. НОГУМАНОВ, А.Н. ШӘВӘЛИЕВ

Татарстан Республикасы Төзүчеләр берлеге һәм бердәмлеге, Татарстан Төзүчеләр берлеге президенты, Татарстан Төзүчеләр бердәмлеге мактаулы президенты, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе
ХАЛИТОВ Рим Шәфыйк улы
вафат булу сәбәпле, мәрхүмнең гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.
Татарстан Республикасының төзелеш тармагын үстерүгә үзеннән зур өлеш керткән фидакарь җитәкченең, югары квалификацияле төзүче, гүзәл кешенең якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

АТНА САЕН БЕР БҮЛӘК

ЯЗЫЛ!
2024 елның беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына языл

4–22 декабрь –
ташламалы бәядән язылу көннәре

П2435 (жомга) >> ~~571 сум 98 тиен~~ **497 сум 34 тиен**

П2409 (сиш., чәрш., жомга) >> ~~1255 сум 86 тиен~~ **1086 сум 18 тиен**

КВИТАНЦИЯНЕ БЕЗГӘ ЖИБӘР!
89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт

БҮЛӘК ОТ!
Атна саен бер приз иясе ачыклана. 21 декабрьдә уйнатылачак бүләк –
ЯҢА ЕЛ КҮЧТӘНӘЧЕ

Бу атна җиңүчесе – Балтач районы Норма авылыннан Нурия Закирова. Котлыйбыз һәм элемтәгә чыгуыгызны үтенәбез!

ҖИҢҮЧЕ БУЛ!

Акциядә катнашучыларны гыйнвар аенда тагын да зуррак бүләкләр көтә

- ТУЗАН СУЫРТКЫЧ
- КЫСКА ДУЛКЫНЛЫ МИЧ
- ИТТАРТКЫЧ
- МУЛЬТИПЕКАРЬ
- ҮТҮК

Тулырак сайтта: vatantat.ru
Акция 2023 елның 29 сентябреннән башлап 2024 елның 10 февраленә кадәр дәвам итәчәк.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Реклама 16+

Беләсең килсә...

1 Россия Президенты вазыйфасына ничә яшьтән сайланырга була?
а) 25;
б) 30;
в) 35.

2 Эглет нәрсә ул?
а) йортның түгәрәк өлеше;
б) шнурның тимер очы;
в) помидор кушылган йомырка тәбәсе.

3 «Шахмат» сүзе фарсы телендә нәрсәне аңлата?
а) юллар ябылды;
б) җиңү килде;
в) король үлде.

4 «Хисләргә бирелә идем мин» җырын кем башкара?
а) Ришат Фазлыйәхмәтов;
б) Илназ Минвәлиев;
в) Илдар Әхмәтов.

Җаваплар: 1. в); 2. б); 3. в); 4. в).



Сканворд җаваплары

Горизонталь: клип, тирес, тамале, чи, бичә, зур, таң, Нух, Аршак, Нил, Рифә, гына, утлы, Ка, Зәкуан, мал, ләм, ары, Рәхимов, еш, зар, сиам, мин, байт.

Вертикаль: кычыткан, күмер, Рига, әзи, ит, уңышлы, Алихан, паб, ир, Ми, КрАЗ, тач, Оса, илә, фук, Вий, ре, Зиннәтулла, ат, Ла, әрем, Сәмрух, сынамыш.

Әз-мәз мәзәк

Балалар бакчасында «сине алырга килделәр» дигән сүзне ишетү бик рәхәт. Әгәр син бу оешманың баш бухгалтеры булмасаң.

***

Һава торышын песиләр әйтә ала. Әгәр песиегезне батареядан алганда ул сезне тырный башлый икән, димәк, салкыннар килә.

***

2023 елны авыр дип санаучылар 2024нең кабисә ел булачагын беләмикән?

***

– Минем сезне кайдадыр күргәнем бар.
– Мин – синең беренче ирең.
– Чынмы? Танымадым. Ә ничек яраталар идем!

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән.
Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 13596 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 366

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+